ЧУТЛЫЙСЫ ДА МУКЛИСЕ
Төзелеш тармагы яңа елга нинди нәтиҗәләр белән керә?
> 2

УКЫП СӨЕНСЕННӘР!
Ябык әдәби конкурсның быелгы җиңүчеләре
> 5

ӘДИЛӘ ХӘСӘНОВА:
«Беренче төп ролем – хан кызы»
> 8

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Тагы да яхшырагы – бернәрсә дә әйтмәү»
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 8–9 (29168–29169) | Сишәмбе | 23 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БУРАННАН СОҢ ТОРМЫШ

Илдар Мөхәммәтҗанов / Лилия Гыймазова коллажы

Яшәргә өйрәнәбез

Транспортны, юлларны, гадәтләнгән тормышыбызны – чыдамлыкка, кешеләрне бердәмлеккә сынап та карады соң бу буранлы көннәр! Сынатмадык шикелле. Соңгы берничә елдагы иң көчле явым-төшем буранлы балачакка алып кайтты, шәһәргә җан кертте, көрәк тотып эшләүнең ни икәнен искә төшерде, юлдагыларга эш арттырды.

Кайда син, өем?

Сала халкы кар һөҗүменә ничек каршы торган?

– Без урамның иң кырыенда яшибез. Кыр булгач, буран бар карны безнең капка төбенә өя, – ди Питрәч районының Шәле авылында яшәүче 41 яшьлек Ләйсән Шәкүрова. – Җитмәсә, өйгә җиһаз китерәселәре бар. Аптырагач, трактор чакырттык. Икенче көнгә тагын шул галәмәт. Якшәмбе көнне ирем Юрий белән кар астыннан юл ясадык. Биеклеге – 2 метр, озынлыгы 11 метрдан артык. Моның өчен 6 сәгатьләп вакыт китте. Көрәкләр сынмады. Кулларны кыймылдатырлык та хәл юк.

Ләйсәннең моңарчы бу кадәр кар күргәне булмаган. Урамдагы «КамАЗ» кадәр «КамАЗ»ны да кар күмә язсын әле?! Урам юлы әле кардан арынмаган. Кибеткә кәҗә сукмагыннан гына йөриләр. Ә теге кар тоннелен җимерергә уйламыйлар. Кыш тагын кәефен күрсәтергә мөмкин бит! Шуңа күрә кар асты юлын су белән катырып куймакчылар. Торсын ла, комачау итми!

Питрәч районының Колкамәр авылында яшәүче Горшуновларның 5–6 метр биеклектәге йорты хәзерге вакытта – кар капкынында. Кар түбә белән тигезләшкән инде. Бары бер ягында гына чыгу юлы бар икән.

– Чыкмадык әле, юл юк бит. Ирем Михаил – тракторчы, ул инде 4–5 көн эшендә юлларда кар эттерә. Мин буранда үзем генә утырдым, – диде Зоя Горшунова. – Түбәдән кар төшеп, тәрәзә ватылмагае дип борчылдым. Утлар да сүнеп алды. Тәрәзәләр кар белән каплангач, дөм караңгы. Шәм кабызып утырырга туры килде.

Зоя апа авылда – социаль хезмәткәр. Үзеннән бигрәк ялгыз яшәүче әби-бабайлар өчен кайгыра ул. Арада өен мичкә утын ягып җылытучы инвалид та бар. Пәнҗешәмбе көнне чишмәдән су ташыган, икмәген, кирәк-ярагын илтеп биргән. Җомгадан бирле барганы юк икән. Сүз уңаеннан, авылда кибет юк. Атнага ике мәртәбә автокибет килә. Авылда сөт тә тапшырып булмый. Авыл халкы юлларны ачмыйлар дип зарлана. Трактор керә алмый. Күршеләр бер-берсе белән хәләхвәл сорашып тора.

Әтнә районы Бахтачы авылының да тынгысыз чагы. Монда кышын тугыз йортта нибары 19 кеше яши. Юл юк, шул сәбәпле балалар мәктәпкә укырга бара алмый. Ире Ирек трактор белән өй тирәсендәге карны эттергән. Әмма шулкадәр карга каршы торырга техниканың көче җитми икән. «Көрәп бетерә торган түгел карны. Башка борчу-хәсрәт бирмәсен инде. Кар ул – муллык», – ди Рәмзия Хөсәенова.

Кыскасы, буранда кешеләр ничек кенә хикмәтләнмәгән. Әлмәт районының Нәдер авылында Гомәровларның улы мунчага утынны чаңгыда ташыган. Мамадыш шәһәрендә яшәүче Гөлшат Исламованың гамәле дә бик кызык тоелды безгә. «Кар өйнең тәрәзәләрен күмде. Урам күренми. Аптырагач, тәрәзәне ачып, кулымны тыгып карадым. Карның калынлыгы – ярты метр чамасы. Күршеләрне карау өчен, агач кашык белән тишек тиштем», – ди ул. Балтач районының Пүскән авылында юл булмагач, сөтне чанага салып илткәннәр. Кызганыч, кайбер авылларда үлем-җитемнәр дә булган. Ни генә булса да, авылда тормыш тукталмаган.

Күмәк көч

Юлчылар, торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре, ничек кенә тырышса да, тротуарларны, юлларны, ишегалларын тулысынча җыештырырга өлгерми. Җыйганын да кая куясың?

«Күмәк көч тау күчерер» дигәнне «кар күчерер» дип үзгәртәсе булыр бугай. Халык ишеп яуган карлы көннәрдә урам себерүчеләргә, юлчыларга ярдәмгә үзе чыкты. Уңай ягы да юк түгел: каткан буыннар язылды, саф һава суланды, күрше белән күрше танышты, бала-чага, интернеттан ял итеп, карда аунады.

«Ричмонд» торак комплексында яшәүче Рамил әйтүенчә, кар алып килгән мәшәкатьләр кешеләрне берләштерде.

Ахыры 3 нче биттә >

Хуплаганнар

Президентлыкка кандидат Владимир Путинның штабы Үзәк сайлау комиссиясенә, сайлауда катнашуга теркәлү өчен, тарафдарларының имзасын җыеп тапшырган. «РИА Новости» хәбәр иткәнчә, ЦИК имзалар белән шыплап тутырылган 95 тартма кабул иткән. Шулай итеп, Владимир Путин үзен үзе тәкъдим итүчеләр арасында имзаларны Үзәк сайлау комиссиясенә беренчеләрдән булып тапшырган.

Штаб рәистәше Владимир Машков әйткәнчә, Путин тарафдарлары законда таләп ителгәннән 10 тапкыр күбрәк имза җыйган. Бу исә халыкның бүгенге Президентны бик югары дәрәҗәдә хуплавы турында сөйли.

Хәзерге вакытта дәүләт башлыгы вазыйфасына 11 кеше дәгъва кыла. Үзәк сайлау комиссиясе өч кандидатны – Леонид Слуцкий, Николай Харитонов һәм Владислав Даванковны теркәгән инде.

Парламентка узмаган партияләрдән кандидатларга – Сергей Малинкович, Борис Надеждин, Андрей Богданов, Сергей Бабурин, Ирина Свиридовага исә 31 гыйнварга кадәр кимендә 100 мең имза җыярга кирәк. Ә үзен үзе тәкъдим итүчеләргә – Владимир Путинга, Рада Русских, Анатолий Баташевка ким дигәндә 300 мең имза җыю таләп ителә.

Үзәк сайлау комиссиясе 10 февральдән дә соңга калмыйча барлык кандидатларны теркәү турында карар кабул итәргә тиеш. Президент сайлау өч көн – 15, 16 һәм 17 мартта узачак.

Авылга күченәләр

Узган елда республикада бер меңнән артыграк кеше ипотекага авылдан торак сатып алган. Кредит күләме барлыгы 4 миллиард сум тәшкил иткән. Алдагы еллардагыга караганда зуррак сан бу.

Авыл ипотекасы белән кызыксынуның артуы 2023 елда программага үзгәрешләр кертелүгә бәйле. Республикада урнашкан күчемсез милек сатып алуга кредитның иң зур күләме ике тапкыр артып, 6 миллион сумга җиткән. Ә инде ипотеканы гаиләдә ир дә, хатын да бер үк вакытта алса, банк биргән акча күләме 12 миллион сумга кадәр тәшкил итәргә мөмкин.

Шулай ук район үзәкләрендә 5 каттан да биегрәк булмаган яңа йортлардан фатир сатып алучыларга кредит бирү яңартылган. Шул рәвешле Арча, Буа, Кукмара һәм Мөслим районнарында фатирлар сатып алынган.

Бер, әмма берәгәйле

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы, ОРВИ көчәю сәбәпле, сәламәтлек саклау буенча бердәм элемтә үзәгенең эшләве турында искәртә. Вируслы инфекция билгеләре күренүгә үк, телефоннан шалтыратып, табибны өйгә чакыртырга мөмкин дигән сүз бу.

Исегезгә төшерәбез: элемтә үзәге узган елның сентябреннән эшли башлады. Моңа кадәр сәламәтлек саклау өлкәсендә булдырылган төрле «кайнар линия»ләрне берләштергән ул. Операторлар барлык медицина оешмаларының мәгълүмат системасына тоташтырылган.

Бердәм элемтә үзәгенә (8(843) 558-03-03) шалтыратып, прививка ясату, диспансеризация узу өчен табибка язылырга, шулай ук табибны өйгә чакыртырга мөмкин.

Элемтә үзәге ачылганнан бирле аңа якынча 16 мең тапкыр шалтыратканнар инде. Ул атна буе тәүлек әйләнәсе эшли.

Хәтәр юл

Узган ел Казанда йөртүчеләрнең каршы як юлга чыгулары сәбәпле, 6 кешенең гомере өзелгән. Татарстан башкаласында юл фаҗигаләрен булдырмый калуга юнәлдерелгән «Каршы як полоса» профилактик чарасы уздырыла.

ЮХИДИ хәбәренә караганда, 2023 елда шәһәрдә юл хәрәкәте кагыйдәсен санга сукмау аркасында 47 шундый авария теркәлгән. Инде әйткәнебезчә, 6 кеше һәлак булган, 71е җәрәхәтләнгән яки имгәнгән.

Каршы як юлга чыгуга бәйле гамәлләрне кисәтүгә юнәлдерелгән чара гыйнварның 22сеннән 31енә кадәр уздырыла. Йөртүчеләр юлларда узу кагыйдәләрен истә тотарга һәм аларны үтәргә тиеш.

Кагыйдәләрне бозган өчен 5 мең сумга кадәр штраф яки 4 айдан 6 айга кадәр машина йөртү хокукыннан мәхрүм итү каралган. Ә инде юл хәрәкәте кагыйдәсен кабат бозучы «права»сыннан 1 елга мәхрүм ителергә мөмкин.

Сәламәтлек

Кисәтү хәерлерәк

Яңа туган балалар санын арттыру, баласызлыкны киметү... Быел диспансеризация программасына әнә шундый максатны күздә тоткан үзгәрешләр гамәлгә керә. Моннан тыш С гепатитына антитәнчекләр барлыгын да тикшерәчәкләр. Бу үзгәрешләр өметләрне акларлармы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәсми саннарга күз салсаң, бүген Россиядә яшәүчеләрнең 17,5 проценты бала сөю бәхетеннән мәхрүм. Бу – илдәге һәр алты кешенең берсе баласызлыктан интегә дигән сүз. Шуның белән беррәттән илдә туучылар саны да кими бара. Узган елның сентябренә алынган соңгы мәгълүматларга караганда, бер ел эчендә илдә туучылар саны 8,4 процентка кимегән. Диспансеризациягә кертелгән яңа үзгәрешләр, иң беренче чиратта, шушы проблемаларны хәл итүне күздә тота.

КФУ Университет клиникасының акушер-гинекологы Резедә Шәрипова моны бик дөрес һәм урынлы үзгәрешләр дип саный.

– Бу үзгәрешләр халыкның репродуктив сәламәтлегенә уңай йогынты ясар дип өметләнәм. Диспансеризациядә моңа кадәр булганнарыннан тыш, хәзер хатын-кызлар өчен күкрәк бизләренә УЗИ, аналык муентыгын тикшерү, җенси юл белән күчә торган инфекцияләргә тикшерү кебек яңа юнәлешләр дә өстәделәр бит. Ир-атларның репродуктив саулыгына да игътибар артты. Алар спермограмма, репродуктив органнарына УЗИ уза. Һәр икесенә С гепатитына тикшеренү узу да мәҗбүри. Моңа кадәр исә әлеге тикшеренүләрне, стандарт рәвештә табибка күренгәннән соң, тар белгечкә юллама алган очракта гына узып була иде. Бу яңалык сәламәтлектәге үзгәрешләрне вакытында ачыклап, күп кенә чирләрне башлангыч чорда ук дәваларга мөмкинлек бирәчәк, – ди табиб.

Диспансеризациянең ул яктан әһәмияте ел саен искәртелеп килә анысы. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, узган ел республикада 1 миллионнан артык кеше диспансеризация узган. Аның барышында 15 мең йөрәк авыруы, 2 меңләп яман шеш очрагы ачыкланган. Һәр ун кешенең берсенә исә теге яки бу чир килеп чыгу куркынычы янавын ачыклаганнар. Бүген Татарстанда элеккечә үк тире, эчәклек, сөт бизе яман шеше иң киң таралган.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Елена БОНДАРЕНКО, «Җәмәгатьчелек фикере – Татарстан» фонды директоры урынбасары:

Берничә ел элек ваемсыз тоелган яшьләрнең хәзер гаделлеккә, мөмкинлекләр тигезлегенә, җәмгыятьне берләштерә алырлык ниндидер идеологик нигезләргә ихтыяҗы артты. 10–20 ел элек өлкәннәр актив иде. Алар «Ватан» дип теләсә нәрсәгә әзер, ә яшьләр пассив иде.

(«Татарстан-24» каналына биргән әңгәмәсеннән)

КЫШКЫ ЯЛ – 2024

Россиядә яшәүчеләр бәйрәм ялларын ничек уздырган? Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре әнә шуны белешкән.

49% >	Дус-иш, якыннар белән очрашкан
43% >	Телевизор караган
24% >	Кунакка барган
22% >	Саф һавада йөргән
13% >	Күңел ачу чараларына йөргән
11% >	Актив ял иткән



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АВЫР ЕЛЛАР

Дөньякүләм вакыйгалар моңарчы күрелмәгән тизлектә һәм киеренкелектә бөтерелә. Зур державаларның икътисадлары өметле түгел. «Кытайда Япония сценарие буенча дефляция һәм яшьләр арасында эшсезлекнең югары дәрәҗәсе күзәтелә. Бу «торгынлык һәм өзелгән өметләр» чорының башы турында сөйли», – дип белдерде икътисад буенча Нобель премиясе лауреаты Пол Кругман. Кытайның үткән елгы үсеш темплары турындагы саннары дөрес түгел, ди чит илләрдәге икътисад белгечләре, ягъни 5,2 процентлык үсеш темпы бармактан суырылган сан димәкче булалар. Процентлы әҗәткә баткан ил өчен бәяләр түбәнәю бизнесның бурычларын түли алмаячагын искәртә.

Бер Кытай гына түгел, Европа икътисады да авыр көннәр кичерә. Немец фермерларына Европаның башка илләре авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре кушылды. Протест Франциядә аеруча көчле темп ала. Германиядә биш ай рәттән инде сәнәгать җитештерүе түбәнәя. АКШның төбәк банкларына яңадан бөлгенлек куркынычы яный.

Икътисад тармагыннан төшенке хәбәрләрне тиктомалдан гына китермибез. Бүген алар зур сугышның прелюдиясе булып тора. Үткән атнаның икенче яртысында гына да планетада берничә зур сугыш учагы дөрләтергә азапландылар. 17 гыйнварга каршы төндә язма авторының телефоны шомлы хәбәрләрдән тынмады. Иран, Пакьстан җирләрендәге «Җейш әл-Гадел» сугышчан төркеменә атабыз дип, баллистик ракеталар очырды. Исламабад моны бәйсез дәүләткә һөҗүм дип бәяләде һәм Тәһран белән дипломатик элемтәләрне өзде. Икенче көнгә инде Пакьстанның хәрби очкычлары Иран күгенә үтеп керде һәм Систан белән Белуҗстан төбәкләрен утка тотты. Беренче карашка зур сугыш башланып китәр төсле иде, әмма ике илдә дә ут астында белуҗ халкы – ирек сөючән күчмәләр калуын күргәч, сәхнә артында килешенгән спектакль генә баруын аңларга мөмкин иде. Шулай булып чыкты да ул: дипломатик мөнәсәбәтләр ничек тиз өзелгән булса, шулай ук тиз торгызылды.

Американың үз иярченнәре белән Йәмәнгә һөҗүмнәре тукталмый, әмма кире нәтиҗә бирә. Кызыл диңгездәге сәүдә трафигын җимергән йәмәнлеләр Якын Көнчыгыштагы өч су сәүдәсе юлын да бикләргә вәгъдә итте: «Әл-Әкъса өчпочмагы» дигән операция башладылар. Хәзер Кызыл диңгез генә түгел, Фарсы култыгы, Һүрмуз бугазы да мишеньгә алынды.

НАТОның хәрби комитеты рәисе, адмирал Роб Бауэр якындагы 20 елда НАТО белән Россия арасында сугыш башланырга мөмкин дигән сүз чыгарды. Германия оборона министры Борис Писториус кораллы конфликт башланырга 5–8 ел вакыт бирә. Бөекбританиянең оборона министры Грант Шапс: «Без сугыштан соңгы чордан сугыш алды чорына күчеп ятабыз», – диде. Якын Көнчыгыштагы хәлләргә Көнбатыш – Россия конфликты күзгә күренмәс җеп белән бәйләнгән шул.

Россиядә

ЮГАРЫ СТАВКАЛАР ТЕЗ АСТЫНА СУГА

Россия икътисады да глобаль проблемалар тәэсирендә туган чирләрдән интегә. Гыйнвар каникулы тәгәлләнер-тәгәлләнмәс, безне йомыркага һәм башка азык-төлеккә бәяләр төшә, дип шатландырдылар. Язма авторы белеште: Татарстанда 10 гыйнварга, чынлап та, алдагы атна белән чагыштырганда тавык йомыркасына уртача бәя 0,14 процентка түбәнәйгән. Бу – 19 тиен, ягъни кесә сизәрлек түгел. Тавык итенең исә килосы 3,29 сумга, ягъни 1,45 процентка очсызланган. Дуңгыз итенә бәя сизелерлек төшкән. Сыер һәм сарык итләре бәяләрне югары үстерә. 17 гыйнварга дуңгыз һәм тавык итләре ел башындагы стартны сакларга тырышканнар, бәя төшү дәвам иткән. Йомырка янәдән 1,76 процентка күтәрелгән. Кыскасы, дефляция башлана дип шатланырга иртә.

Кулланучы өчен шатлык булса, процентлы икътисадта бәяләр төшү – җитештерүчеләр өчен катастрофа ул. Берьюлы ике проблема тудыра: ихтыяҗ кими, ягъни азрак җитештерәсең, арзангарак сатасың. Процентларны кем һәм ничек түли андый шартларда?

Россия Үзәк банкының төп ставкасы исә – дөнья масштабында караганда иң югарылардан. Без Аргентина белән Төркиядән генә калышабыз. 2023 елда бизнес процент ставкасы күтәрелүгә артык зур игътибар бирмәгән иде. Бүтән проблемалар бугаздан тоткан иде. Дүртенче кварталда сәнәгать предприятиеләренең бары тик 13 проценты гына ставка зур булуның үсешне чикләвен белдергән. Беренче номерлы проблема булып квалификацияле кадрлар җитмәү торган. Сумның очсызлануыннан да зарланганнар. Ә югары процентлар проблемасы – тугызынчы урында гына.

Яңа елга аяк басу белән кәефләр үзгәргән. Предприятиеләрнең 24 проценты хәзер, кредит ставкасы үсешне тоткарлый, дип саный. Проблема алтынчы урынга күтәрелгән.

Путин үткән елда Россиядә 110 миллион квадрат метр торак сафка басканны әйтеп шатландырган иде. Бу абсолют рекордның быел кабатлануы икеле. Ипотека базары торгынлык чорына кереп бара, чөнки банклар үткән ел ахырында ук яңа торак алу өчен кредит сорап килүчеләрнең һәр икенчесен кире борып торды. 2024 елда бу юнәлеш көчәячәк. Алганын түли алмаучылар саны да артыр, дип фаразлап була.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ҖИДЕ КАТ УЙЛАП ТӨЗИСЕ

Төзүчеләрдән яңа рекорд, тузган торбалар һәм министрның «яшереп куйган» саннары. Башкалада Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының еллык коллегия утырышы узды. Чарада Россия төзелеш һәм ТКХ министры Ирек Фәйзуллин, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты.

Республика төзүчеләренә тел-теш тидерерлек түгел. Бу хакта Ирек Фәйзуллин да әйтте.

– Узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстанда төзелеш эшләре 700 миллиард сум күләмендә бәяләнә. Бу – бик зур сан, – диде үзе дә күп еллар республиканың төзелеш тармагын җитәкләгән Мәскәү кунагы.

Татарстанда өченче ел рәттән 3 миллион квадрат метрдан да күбрәк торак кулланышка тапшырылуын искә алып: «Марат Айзатуллин бөтенесен дә әйтеп бетерми әле, яшереп куйган саннары бар», – дип тә өстәде. Форсаттан файдаланып, Ирек Фәйзуллин республикага илнең яңа төбәкләрендә алып барылган эш өчен рәхмәт әйтте. Билгеле булганча, безнең төзүчеләр Лисичанск, Рубежное һәм Мариуполь шәһәрләрен торгызуда катнаша. «Әлеге эштә бернинди дә тоткарлык юк», – диде федераль министр.

Татарстан төзүчеләре елдан-ел тырышып эшли. Чираттагы рекордны куйганнар әнә. 2022 елда республикада 3 миллион 93 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылса, узган ел йомгаклары буенча әлеге сан 3 миллион 436 мең квадрат метрга җиткән.

– Әлеге күрсәткеч буенча Татарстан Идел буе федераль округында беренчелекне саклап калды. Ил күләмендә исә без – алтынчы урында, – диде Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин. – Төзелгән торакны сату күрсәткече дә тотрыклы үсә. Аны асылда ташламалы ипотекалар тәэмин итә, әлбәттә. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, Татарстанда ипотека заемнары 67,2 процентка арткан. Яңа салынган торак базарында үсеш – 64,7 процент.

Алга таба да тик торырга җыенмыйлар. Министр әйтүенчә, республикада күпфатирлы йортлар төзелешендә эш җитәрлек.

– Бүген 123 төзелеш оешмасы 303 күпфатирлы йорт сала. Аларның гомуми мәйданы 2 миллион 582 мең квадрат метр тәшкил итәчәк. Төзелеш эшләренә исә 498 рөхсәт бирелгән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 6 процентка күбрәк, – диде министр.

Тагын бер сөенеч: былтыр Татарстанда «сакаллы» төзелешләрне кулланышка тапшырып бетергәннәр. Сүз өлешләп төзелештә алданучылар турында бара. Декабрьдә генә моңа бәйле соңгы ике объектта – башкалада урнашкан машина кую урыннарында эш беткән. 2003–2007 елларда республикада өлешләп төзүгә бәйле 146 «сакаллы» төзелешне кулланышка тапшырганнар. Алардан 19 меңгә якын алданган өлешче торак алган.

Бу хакта сөйләгәндә, утырышта катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов алга таба уяурак булырга киңәш итте.

– Торак төзелешендә бераз гына йомшаклык күрсәтсәк, алданган өлешчеләр тагын килеп чыгарга мөмкин. Тәмамланмаган төзелешләр үзләреннән-үзләре пәйда булмады бит. Муниципаль берәмлекләр, монда сезнең дә катнашыгыз бар. Барысын да алдан уйлап бетереп булмый, әлбәттә. Әмма моның зур җаваплылык икәнен аңларга, кем белән эшләгәнне белеп торырга кирәк, – диде ул.

Төзелүче торакның сыйфатына да игътибарны арттырырга кушты.

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов район вәкилләренә махсус техника ачкычларын тапшырды. Быелгы кышта мондый «тимер ат»ларның кадере аеруча артты. Барлыгы 45 данә техника яңа хуҗалы булды. Гомумән алганда, 2017–2021 елларда республика районнарына 500дән артык махсус коммуналь техника тапшырылган.

– Төзелеш оешмасы ул акчасын ала да китә, ә анналары барлык кыенлыкларны җирле хакимият, республика хәл итәргә, биредә яшәүчеләрне кайгыртырга тиеш. Шуңа күрә бу мәсьәләдә билгеле бер тәртип булырга тиеш. Салынып бетмәгән яки сыйфатсыз төзелешләр баш бәласенә әйләнмәсен, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Төзелеш тармагы шөкер итәрлек булса, коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр чаң суга.

– Җылылык белән тәэмин итү тармагының хәле яхшылардан түгел, – диде утырышта «Татэнерго» оешмасы генераль директоры Рәүзил Хаҗиев. – Республиканың зур шәһәрләрендә җылылык белән тәэмин итү челтәрләре 50 проценттан да күбрәккә тузган. Казанда әлеге күрсәткеч – 55, Чаллыда – 56, Түбән Камада – 71, Бөгелмәдә – 60, Зәйдә 54 процент тәшкил итә.

Сәбәпләрен дә әйттеләр. Әлеге дә баягы – акча җитми.

– 2023 елда «Татэнерго» җылылык челтәрләрен төзекләндерү һәм торгызуга 3,1 миллиард сум акча юнәлтте, тагын 1,8 миллиард сум акча җылылык чыганакларына тотылды, – диде Рәүзил Хаҗиев.

Күңелендәгесен әйтеп: «Бүген юллар салуга тотылган акчага кызыгабыз», – диде ул. Республикада яшәүчеләрне җылылык белән тәэмин итүче оешма җитәкчесе фикеренчә, Татарстанда капиталь ремонт мәсьәләсен хәл иткән кебек, торак йортларның инженер челтәрләрен төзекләндерүгә бәйле программа да уйлап табарга кирәк.

Мисал эзләп ерак йөрисе дә юк, коллегия узган көнне генә башкалада утыз ел элек төзелгән инженер челтәрендә авария чыгып, Әмирхан проспектын су басты. Аңа кадәр Чистай халкы сусыз калган иде. Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская да, утырышта чыгыш ясаганда, республикада яшәүчеләрдән ТКХ һәм тышкы төзекләндерүгә бәйле килеп ирешкән шикаятьләр саны артуын искәртте. Гади халыкның да күңеле тулган, ахры. Рөстәм Миңнеханов тармакның «авырткан җир»ен хәл итү юлларын эзләргә кушты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Кисәтү хәерлерәк

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Диспансеризация исә барлык төр яман шешләрнең яртысын ачыкларга ярдәм итә, ди белгечләр. Аерым алганда, диспансеризация программасы кысасында каралган скрининг технологияләре ярдәмендә сөт бизләре, аналык муентыгы, мәни бизе, эчәк яман шешен 1–2 стадиядә чакта ук ачыкларга мөмкин.

Республика клиник хастаханәсенең табиб-терапевты Анастасия Яковлева әйтүенчә, чиргә бәйле вазгыятьне үзгәртү өчен тикшерену программасына үзгәрешләр кертү генә җитми.

– Яшерен-батырын түгел, бүген күпләр диспансеризациягә барырга атлыгып тормый. Моны ниндидер өстәмә мәшәкать кебек кабул итә. Шуңа күрә диспансеризациягә кертелгән үзгәрешләр белән беррәттән, кешеләрнең үз саулыгына җаваплырак карый башлавы да кирәк, – ди табиб. – Чир башлангыч чорда табылса, аны тулысынча җиңү ихтималы да шулкадәр югарырак бит. Шул ук балага уза алмау, нәселсезлек проблемалары еш кына инфекция, бигрәк тә җенси юл белән күчә торган инфекцияле авырулар нәтиҗәсендә килеп чыга. Алар вакытында ачыкланса, кешенең репродуктив сәламәтлеге дә аксамас иде. Диспансеризациягә кертелгән яңа үзгәрешләр шушы проблеманы юкка чыгарыр, илдә туган балалар саны да артыр дип өметләнәсе килә.

Сүз уңаеннан, якын арада кыз балаларның саулыгына игътибарны арттырмакчылар. Моңа кадәр алар хатын-кыз табибына беренче тапкыр 14 яшендә күренә иде. Хәзер алар табиб бусагасын 13 яшь тулуга атлап керәчәк. 10 нчы номерлы шәһәр балалар хастаханәсе баш табибы Лилия Мөхәммәтгатова бу тәкъдимне сөенеп кабул иткән.

– Яшь буынның киләчәге, сәламәтлеге турында сөйлибез икән, без иң беренче чиратта кыз һәм малайларның саулыгын кайгыртырга тиеш. Аларның репродуктив сәламәтлеген мәктәптә укыганда ук кайгыртырга кирәк. Шуңа күрә быел 15–17 яшьлек кыз һәм ир балаларның гинеколог һәм урологларга күренеп тору күрсәткечен 78 проценттан 83 процентка җиткерәсе иде. Яңа туган сабыйлар, балалар арасында үлем-китем очракларын киметү дә зарур. Безнең тормыш, сәламәтлек саклау тармагының дәрәҗәсен билгели торган күрсәткечләрнең берсе бу, – ди табиб.

Белеп тор!

ДИСПАНСЕРИЗАЦИЯ ИКЕ ЭТАПТА УЗА

I этап

✓ Иң элек кешедән диспансеризация үтү өчен ризалык алына. Аннан ул анкета тутыра. Анда ул үзенең яшәү, туклану рәвеше, начар гадәтләре, нәселдән килгән авырулары турында яза.

✓ Буй, авырлык, бил әйләнәсе үлчәнә. Кан басымы тикшерелә. Кандагы глюкоза һәм холестерин дәрәҗәсе карала.

✓ 60 яшьтән узганнарның күз басымы үлчәнә. 36 яшьтән олы ир-атлар, 45 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар ЭКГ үтә. 30–60 яшьтәге хатын-кызлар яман шешне ачыклауга мазок тапшыра. 39 яшьтән узган хатын-кызларга маммография үтә.

✓ Тизәк анализы (яшерен кан булу) тикшерелә. Ир-атларга ПСА анализы бирәсе.

✓ Барлык кешегә да флюорография каралган.

II этап

✓ Теге яки бу чир барлыгы турында шик туса, ул тагын да җентеклерәк тикшерену узарга тиеш. Мәсәлән, баш миенең кан йөрешендәге тайпылышларга шик булганда, неврологка күренәсе булачак. Ир-атларда ПСА күрсәткече артык икән, кичекмәстән, урологка яки хирургка күрену кирәк. Тизәктә яшерен кан табылса, колопроктолог яисә хирургка юллама бирелә. Тын юллары авыруларына шик булганда, спирометрия (ФВД) уздырыла. Маммография яки гинекология мазогы анализында үзгәрешләр барлыгы ачыкланса, гинекологка күренәсе.

✓ Шуннан соң участок табибы алга таба тикшерену үтү өчен табибларга юллама бирергә мөмкин. Берәр җитди авыру ачыкланса, үзең беркетелгән участокта диспансер күзәтүгә алынып, даими рәвештә үз участок табибыңа күренеп торырга кирәк булачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САН БЕЛӘН САНЛАШУ

Нәтиҗә

Дәүләт хезмәтләреннән онлайн файдалану мөмкинлеген арттырырга, интернет тотмаган юлларны элемтәле итәргә, киберһөҗүмнәрне булдырмаска. Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин тармак нәтиҗәләре турында хисап тотты.

Уңыш һәм ният

Санлы технологияләрнең икътисадка да, көнкүрешкә дә китергән файдасы турында саннар да сөйли. Күз салыйк.

▶ Тармакның Татарстанның тулай төбәк продуктына керткән өлеше – **3** процент.
▶ Керем фаразы – **177** млрд сум.
▶ Мобиль элемтә операторларының инвестицияләре – **2,1** млрд сум.
▶ Ике ел эчендә **6** млрд сумнан артык суммага дәүләтнең яңа инфраструктура IT проектларын булдыру хупланды. Моңа техника сатып алу да, мәгълүмат системаларын булдыру, камилләштерү эшләре дә кергән.
▶ Интернет республика хуҗалыкларының **83** процентында бар. Бер елда **71** мең яңа абонент кушылган.
▶ Халыкта **8** миллионнан артык смартфон һәм планшет бар.
▶ **12,2** млн киберһөҗүм булдырмый калынган.
▶ «Имин шәһәр» комплексы кысасында быел йөзләрне тану функциясе белән тагын **1** мең видеокамера урнаштыру планлаштырыла.

Элемтә димәктән. Олы юлларда интернет, элемтә тотмау әле дә борчыган мәсьәлә булып кала бирә. Айрат Хәйруллин әйтүенчә, элемтә станцияләре төзелә тора (М7 трассасында 14 станция сафка баскан). 2024 елда 1175 төзелергә тиеш. М12 трассасында да 16 телекоммуникация баганасы урнаштырылачак.

Микроэлектроника тармагын үстерү хыялы да бар. Моның өчен инвестицияләр кирәк, әлбәттә. Министр федераль ярдәмгә ышана. Аны ишеткәннәрдер дигән өметтә торабыз.

Рәис фикере

Йомгаклау коллегиясендә катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Хәйруллин командасына, министр сүзе белән әйтсәк, кыйммәтле киңәшләрен җиткерде.

! 2023 елда республикада бик күп киберһөҗүмнәр булган. 2024 елда Татарстанда көтелгән чараларны исәпкә алсак, мәгълүмати куркынычсызлык бар көчкә тәэмин ителергә тиеш.

! Билгеле булганча, дәүләт учреждениеләрен «Астра Линукс» операцион системасына күчерү максаты тора. Алексеевск, Алабуга, Яшел Үзән, Буа, Кайбыч районнары, Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты әле бу эшне башламаган да. Кичекмәстән башларга кушылды аларга.

! Дәүләт хезмәтләреннән электрон файдалану вакытын ике тапкыр киметергә, хезмәт күрсәтү эшен тизләтергә.

! Электрон мәгариф системасына бәйле сораулар күп. Аңламаганны аңлатырга, системаны җайга салырга кирәк.

! IT парклар һәр районда булырга тиеш.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

tatarstan.ru

Дмитрий ЧЕРНЫШЕНКО,
Россия вице-премьеры:
– Татарстан IT тармакка ярдәм итүгә кагылышлы барлык федераль программаларда да актив катнаша, төбәк программалары эшли. Республика җитәкчелеге тармак үсешенә зур көч куя һәм акча бирә. Татарстан – цифрлы трансформация буенча инде ничәнче ел илнең лидерлары рәтендә. Төбәккә санлы мөмкинлекләрнең үтеп керү һәм кулланылу дәрәҗәсе зур. Татарстан IT өлкәдә вакансияләр саны һәм резюме буенча бишлектә, IT белгечләргә бирелә торган ташламалы ипотеканы да биредә ешрак алалар (Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан кала).

БУРАННАН СОҢ ТОРМЫШ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Кар көрәргә пенсионерлар да, хатын-кызлар да чыкты. Битараф калмаган кешеләргә зур рәхмәт. Кирәк-ягракларның күбесен идарәче компания үзе биреп торды. Күпләр: «Мин ни өчен чыгып чистартырга тиеш? Мин бит торак-коммуналь хезмәтләр өчен түлим!» – ди. Әмма табигатькә каршы барып булмый инде ул. Урам себерүчеләр дә барысына да өлгерми. Иртәдән кичкә кадәр кар көри бит алар. Бар нәрсә дә акча белән бәяләнми! Кешелекле булырга кирәк.

Чаллыда да күмәк тырышлык нәтиҗә биргән. Кар көчле яуган көннәрдә тирә-юньне кардан чистарту эшенә студентлар һәм мәктәп укучылары да, хәтта зур предприятиенең эшчеләре, директорлары да кушылган.

Сүз уңаеннан, өмәләр республиканың барлык районнарында да диярлек оештырылган. Көрәк, шәхси тракторлар, халык – барысы да карга каршы хезмәткә!

М12 трассасында да булды хәлләр! Кайбыч районы башлыгы урынбасары Рәмис Хәялиев әйтүенчә, трассага бу бураннар кыенлыклар өстәгән.

– Беренчедән, ул тышкы яктан да, эчке яктан да бик биек барьерлар белән әйләндереп алынган. Алар үзеннән-үзе карны тоткарлаучы булып торалар. Көчле буран карны сыртлап сала. Икенчедән, юл шактый киң булса да, беренче полосада баручы машинаны узарга икенче полосадагысы килеп басса, икәү бергә кысылалар, нәтиҗәдә бөке барлыкка килә. Ни алга, ни артка китә алмыйлар. Әле бит М12дә теләсә кайсы якка рәхәтләнеп йөреп тә булмый, – диде ул. – Ярдәм чараларын күрдек. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы җылыту һәм ашату өчен махсус чатырларын бирде. Аларны алып кайтып, Олы Кайбыч авылы янындагы зур парковка янәшәсенә урнаштырдык. Ашау-эчү якларын район үзе кайгыртты. Ул бит әле пунктны китереп куйдык та, барысы да шунда килеп керде дигән сүз түгел. Машиналарның төрлесе төрле ераклыкта. Кайберләренең ягулыклары беткән. Кайберләре баскан урыннан селкенә дә алмый: алда да, артта да, ян-якта да машина. Аларны җыеп йөрүгә Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәте һәм М12 сафка басу уңаеннан «Автодор» оештырган авария комиссарлары хезмәткәрләре зур көч куйды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Буш тормас

Буран юлларны гына түгел, кибет киштәләрендәге ризыкларны да «себерде». Федераль трассалар ябылу сәбәпле, йөк машиналары азык-төлекне бүлеп бирү үзәкләренә китереп җиткерә алмады. Шунлыктан ял көннәрендә халык күпләп йөри торган кибетләргә кергән кешеләр кайбер төр ризыкларның юклыгыннан зарланды. Әйтик, яшелчә һәм җиләк-җимеш, йомырка, сөт продукциясенең барлык кибетләргә булмавы ачыкланды. Алар урынына сатып алучыларны бушаган киштәләр генә каршы алды.

– Кичә әни үзебезнең яндагы берничә кибеткә кереп чыккан, тик берсендә дә йомырка булмаган. Эштән кайтканда үзем дә юл уңаендагы кибетләргә кереп чыгарга булдым. Чыннан да, беренче кергән «Магнит» кибетендә кишер дә, йомырка да юк иде. Сәбәбен сатучыдан сорагач, ул: «Мондый һава шартларында йомырканы китереп җиткерә алмадылар, әлбәттә. Анысы гына түгел, Яшел Үзәннән сөт тә китерә алмыйлар әле», – диде. Ярый әле янәшәдәге башка кибеттә йомырка да, кирәкле яшелчәләр дә булды, – диде Казаннан Гамбәрия Мотыйгуллина.

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат үзәге «ВТ»га хәбәр иткәнчә, хәзерге вакытта бөтен тырышлык юлларны, ишегалларын һәм тротуарларны кардан арындыруга куела.

– Якшәмбе кичен йөк машиналары һәм автобуслар өчен юлларны ачтылар. Шуннан соң оешмалар товарларны бүлеп бирү үзәкләренә һәм кибетләргә китереп бушата башлады. Вазгыять тотрыклана, шушы араларда кибет киштәләрендә кирәкле барлык төр продукция дә булачак, – диделәр министрлыкта.

Күз ачкысыз кар-буран, җил-давыл булса да, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре эштән туктап тормады, чөнки терлеккә вакытында ашарга бирергә, тиресен түгәргә, әйләнә-тирәне кардан чистартып торырга кирәк.

Соңгы өч көндә Арча җирлегендә дә 41,5 мм кар явып узган. Айлык норма исә 35 миллиметрны тәшкил итә. Шулай булуга карамастан, терлекчелек комплекслары көндәлек тәртиптә эшләгән, әллә нинди зур үзгәрешләр кертерлек булмаган.

– Вак-төяк мәшәкатьләре булды анысы, – диде безгә бу уңайдан районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ленар Абдуллин. – Буранда ут бетеп борчыган чаклар булды. Көчле җил бер склад түбәсен сүтә башлаган иде. Ферма тирәләренә, тирес түгәргә гел юллар ачып торылды. Авыл юлларын ачарга да күпчелек очракларда хуҗалык техникасы җәлеп ителде. Үзебез дә тик ятмыйбыз: дүшәмбе районда кар җыю буенча өмә игълан ителде. Районның барлык җитәкчелеге кар көрибез, халыкка уңай мохит тудыру максатыннан, тротуарларны чистартабыз.

Республиканың берничә районында эшләүче «Август-Агро» компаниясе карамагындагы комплекслар да гадәти режимда эшләгән.

– Терлекчелектә ял да, читтән торып эшләү дә каралмаган, эшчеләр тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, теләсә кайсы һава торышында эшли, – диде оешманың генераль директоры Наталия Козлова. – Товарлыклы сөтчелек комплекслары гадәттәгечә эшли. Юллардагы, ферма тирәләрендәге карларны да вакытында җыештырып тордылар. Шулай итеп, территорияне чистарту буенча өстәмә мәшәкатьләрдән кала, һава торышы терлекчелеккә берничек тә тәэсир итмәде.

Кем җаваплы?

Һава торышының көйсезлеге самолетта очучыларның да кәефен кырды булса кирәк. Кемнеңдер рейслары кичектерелде, кемнәр бөтенләй теләгән җиренә очмады. Андый очракта хокук сүзе нинди булыр? «ВТ» юристы Булат Закировтан шуны сорадык.

– Әгәр билетны үзегез сатып алсагыз, ягъни авиаперевозчик белән килешү төзесәгез, аны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык авиакомпаниягә йөкләнә. Шулай итеп, очкыч хуҗасы гаебе белән рейс һава торышы, техник һәм башка сәбәпләр аркасында тоткарланганда яки туктатылганда, шулай ук маршрут үзгәргәндә, пассажирлар өчен түбәндәге бушлай хезмәтләр оештырылырга тиеш: җиде яшькә кадәрге балалы пассажирга ана һәм бала бүлмәсен бирү; очышны ике сәгатьтән артык көткәндә ике тапкыр телефоннан шалтырату яки ике электрон хат җибәрү мөмкинлеге тудыру; рейсны ике сәгатьтән артык көткәндә салкын эчемлекләр белән тәэмин итү; аерым очракларда кайнар ризык белән тәэмин итү; рейсны көндез сигез сәгатьтән артык көткәндә һәм төнлә алты сәгатьтән артык көткәндә пассажирларны кунакханәгә урнаштыру; аэропорттан кунакханәгә һәм кунакханәдән аэропортка транспорт белән китерү; багаж саклауны оештыру.

Әгәр пассажир очыштан баш тартырга мәҗбүр икән, аңа авиакомпания вәкиленә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул кәгазь билетта тиешле билге ясаячак яки махсус документ бирәчәк. Компенсацияне күчерергә кирәк булган счетны күрсәтеп, гариза языла. Компенсация 60 көн эчендә күчерелергә тиеш. Очышның тоткарлануы яки туктатылуы турында мәгълүмат белән таблоны фотога төшерү кирәк, бу судта булышачак. Әгәр очыш вакыты үзгәрсә, пассажир түләгән бөтен сумманы кире алырга хокуклы. Әгәр очыш өлешчә генә башкарылган булса, аңа акча өлешчә кайтарыла.

P.S. Җырдагыча: «Тышта буран булса булсын, өйдә буран булмасын!» Һәр нәрсәнең уңай ягын күрергә өйрәник. Таш та түгел, хәсрәт тә түгел бит, кар ява. Димәк, муллык ява.

Сәрия МИФТАХОВА, Зөһрә САДЫЙКОВА,
Фәния ӘХМӘТҖАНОВА,
Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Карлы көннәр – саннарда

- Башкалада 17 гыйнвардан башлап 49 мм явым-төшем булган. Бу – айлык норманың 106 проценты.
- Кар эретү пунктлары көчәйтелгән режимда эшләгән. Бер тәүлеккә 11 мең тоннадан артык кар кабул ителгән (гадәти көннәрдә – 8 мең тонна).
- Шәһәрдән 157 мең тонна кар чыгарылган.
- 6 мең тонна реагент һәм ком-тоз кушылмасы файдаланылган.

Фикер

Рәис ШӘКУРОВ, халык синоптигы:
– 4–5 ел инде юньле буран күргән юк иде. Кар бит ул – икмәк. Яусын, кыш карлы булырга тиеш. Тик шул ягы гына борчый: явым-төшем артыкка китсә, җәен давыллар, су басуларга китерергә мөмкин. Бураннардан соң салкыннар башлана. Алда – хут суыклары (19 февральдән 19 мартка кадәр). Ул суыклар кирәк. Бу очракта җәй бик яхшы киләчәк. Быелгы җәй матур килер: яңгыры да вакытында явар, җиле дә вакытында исәр, дип фаразлый ул. Икмәк булса, ит тә, сөт тә булыр.

«ВТ»НЫҢ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАР ФИКЕРЕ

Шәргия ФӘТИЕВА:
«Быел кар күп дисәләр дә, без үскәндәге кебек түгел. Балачакта әнинең сеңелләренә барырга ярата идем. Чөнки аларның өен нишләптер кар баса иде. Шунлыктан веранда ишеген көч-хәл белән ачып, баскыч ясап, өскә менеп, өй түбәсе буйлап йөриләр иде. Дөрес, бала-чагага кызык булгандыр, олыларга – олы бәла иде шул…»

Наилә ИБРАҺИМОВА:
«Яртысы да яумады әле элеккеге карның. Чүт кенә кар яуса да исләре китә! Өчәр көн күз ачкысыз буран була иде. Яусын, куанычы белән яусын! Карга гына түзәргә була».

Халисә ФӘТТАХОВА-ФӘСӘХОВА:
«2023 елның җәй айларында елгалар корыган иде, яусын әле!»

БУ КЫЗЫК!

«Авито» игъланнар сайтына күз салдык. Тракторчы, кар көрәү хезмәтен күрсәтүчеләр бу эшне ничә сумга башкара икән?

Тракторчы	**1000 сумнан** башлана (сәгате)
Көрәк белән кар җыештыру	**700 сумнан** башлана (сәгате)
Махсус техника белән кар җыештыру	**2500 сумнан** башлана
Түбәне кардан чистарту	**40 сум** (квадрат метры)
Машинаны кардан чыгарырга ярдәм итү	**1500 сумнан** башлана

Таксистлар да бу арада яхшы гына акча эшләде. Һава торышы сәбәпле тарифлар уйнаган көннәрдә сменасына 74 мең сум акча эшләүчеләр дә булган.
Бу – 200 заказ үтәгән таксист акчасы.

Авыл фәлсәфәсе

«Яз көне эреп бетәсенә ышанмый башладым»

Башка чакта берәрсе буран, кар күп дип зарлана башласа, авыл кешесенең икенчесе: «Бер елгы кар икенче елга калмый әле, яз көне эреп бетә», – ди торган иде. Соңгы бураннар, дөресрәге, алардан соңгы кар белән көрәшкән көннәр аларның да фикерен үзгәртте. «Яз көне эреп бетәсенә дә ышанмый башладым», – ди өч көн кар ташып, көрәп алҗыган танышым.

Ә мин буранның икенче көнендә үк иремә: «Кичәге романтиклар кайда икән? Бүген нәрсә дип «сайрыйлар» икән? – дим. – Алайса, «безнең балачак бураннары» дип, хисләнеп, бөтен «Ватсап»ны тутырганнар иде. Балачакта, билгеле, бураннар кызык, күңелле булгандыр. Безгә дә кызык кына иде. Уеннан кайтып кермәдек шул. Әниләргә бу бураннар бер дә кызык булмагандыр…»

Иртән торуга, каршыдагы ике як күршеләрне кардан казып чыгара иде әни, аннан үзебездә көрәргә кирәк. Суык дип тә, буран дип тә эштән каласы түгел, анда да физик эш… Су буена юлны көрәп, бәке тишеп, аннан су да ташырга, көн буе утын сүндермичә, мичен ягарга, көлен ташырга, абзар тулы малын карарга кирәк… Аларына да, һич югы, саламын да бирмәгәннәр. Кыш буе, кичләрен күрше колхоз басуыннан (үзләренекенә тиярgә курыкканнардыр инде) баш өстенә күтәреп ташыйсы. Әнә шундый буранлы бер кичтә адашуларын, төн уртасына кадәр басуда салам күтәреп йөрүләрен (әмма аны ташламаганнар!), ярый әле, бәхетләренә, буран бераз тынып, күрше авыл утлары җемелдәп күренгәч кенә юл табуларын буран булган саен исенә төшерә әни. И-и-и, җаннарым, ни хәлләр түзгәннәр диген… Кая анда романтика! «Кышыннан да бигрәк язы яман була иде», – ди әни.

Быел да ул, тәрәзәдән өченче көн рәттән дулаган буранны, без һәм күршеләр көрәп, ташып өйгән кар тауларын күреп, инде яз өчен борчыла. Басудан кинәт су төшеп, басмасмы икән, ди (андый хәлләр дә булды), ничекләр канаулар казырсыз, ди. Соңгылары бигрәк үзәкләренә үткән, ахры. Ул чакта бит, хәзерге кебек, урамнарны кардан чистарту юк. Уртасыннан юл ачалар да, язга кадәр ике көрт арасыннан йөрисе, машина килсә, кая гына барыйм икән дип, кереп калыр урын эзлисе… Кайда ничектер, хәзер безнең үзебездә ничә еллар инде юллар идарәсе авыл урамының үзләренә караган өлешендә, карлар күбәюгә, аларны машиналар белән авыл читенә ташый (сүз уңаеннан, аларга рәхмәттән башка сүз юк: буранлы көннәрдә әллә ничә кат чистартып, юлыбызны киң итеп ачып тордылар). Шуңа күрә канаулар казу шул дәрәҗәдә авыр, мәшәкатьле эш кебек тоелмый. Ә теге чорда… Кыш буе өелгән кимендә икешәр метрлы карны бер капка төбеннән икенчесенә кадәр канаулар казып тоташтырырга кирәк. Бездә, мәрхүм Мулланур абыйлар белән ике ара шактый ерак, яртысын алар, яртысын безнекеләр казыган.

Хәер, быелгы бураннарда да беренче көнендә генә кызык, күңелле тоелды кебек. «Бетә торган кар түгел бу», «Көрәүдән, чистартудан мәгънә юк», «Кар күмеп китсә дә бүтән чыкмыйм», – дип керә дә бераздан тагын көрәгенә ябыша авыл кешесе. Дөрес, сукмак кына салып, трактордан чистарттырырбыз әле, диючеләр дә бар. Шөкер, шәхси тракторлар ул яктан да бик шәп. Күмәк хуҗалык тракторы авылның икенче өлешен (әйткәнемчә, бер өлеше юллар идарәсенә карый) даими чистартып торса, тыкрыкларда яшәүче хуҗалыкларга ярдәмгә алар килә. Әмма беренче көнге буранда күршедәге ике трактор да карга күмелеп калган иде. Башта тракторны казып алдык, диештеләр.

Үзара хәл белешүләр: «Карга күмелеп калмадыгызмы?» – диеп сорашудан башланса, очрашсак та, сөйләшер өчен төп тема шул булды. Кемдер «Ур-ра! Гаражны таптык», – дип сөенече белән уртаклашты, кемдер: «Мунчаны казып алдык», – диде, кемдер кар тоннеленә кунакка чакырды, кемдер: «Рәхмәт, бер кабар хәлем юк», – дип баш тартты.

Ишегалларындагы, каралтыдагы карны урамга түгел, бакчаларга ташыйбыз бит, юлны гел чистартып торгач, капка төпләренә дә ул кадәр салмады. Әз генә җил чыкса да, буран башлана торган иде безнең очта. Дистә еллап элек урамыбызга параллель итеп, бераз читтә нарат-чыршылар утырткannar иде. Ул посадка инде биек, куе булып үсте. Алар да коткарды безне бураннан.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Шәһәр урамнарында менә шулай көрәүчеләр дә бар иде.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Компьютер һәм матур язу

Компьютер һәм гаджетлар китергән уңайлыкларның берсе – теләсә кайсы текстны, текстны гына түгел, бер җөмләдән торган хәбәрне дә басма хәрефләр белән җыю һәм кирәк җиргә озату яисә саклау мөмкинлеге. Грамматика дип тә артык кайгырасы түгел – текст редакторы син язганны карап, хаталарыңны төзәтеп, аз дигәндә аларны күрсәтеп бара. Электрон почта теләсә нинди күләмдәге язманы секундында адресатка илтә дә җиткерә. Бу инде дәфтәр битенә кулдан хат язып утыру, аны конвертка тыгып, ябыштырып, почта тартмасына илтеп салу, фәлән көн үткәч кенә хатның тиешле кеше кулына эләгүе түгел. Тик алай кыланган вакытлар барыбер сагындыра. Чөнки ул рәвешле аралашуның үз рәхәте, тәме, үз өстенлекләре бар иде. Андый хатлар хислерәк, ихласрак, җылырак иде, дисәм, арттырмам.

Бүген, ягъни 23 гыйнвар – Халыкара кулдан язу көне. Аны башкача Почерк көне дип тә атыйлар. Почерк – бу кәлимә дә гаджетлар гасырына кергәч, азрак кулланыла, аз әйтелә кебек. Ә бит һәр кешенең кабатланмас үз кулы, почеркы булганлыгы мәгълүм. Әле почеркка карап, кешенең холкын, ул гынамы, акыл сәләтен билгеләп була, дип сөйлиләр иде. Бәлки чыннан да булгандыр. Чөнки ул һәр кеше өчен уникаль. Хәзергесен белмим, без укыганда мәктәптә, махсус кертелгән дип әйтикме, «матур язу» дип аталган дәресләр дә бар иде. Каләмне карага манып, тырыша-тырыша сырлаган хәрефләрдән, сүзләрдән торган матур язу дәфтәрен әле дә кадерләп саклыйм. Арифметика дәфтәренең дә берсе исән. Шунысында бүгенге яшьләр ни-нәрсә икәнен бөтенләй дә белмәгән киптергеч (промокашка) дип аталган кәгазь кисәге дә нindидер хикмәт белән исән калган.

Вузларда укучылар да лекцияләрне әлегә кулдан яза дип беләм. Һәм шуның белән шул. Укып бетерүгә, эштә булсын, тормыш-көнкүрештә булсын, без кулдан язуны, кулдан язылган текстларны хәзер бөтенләй диярлек кулланмыйбыз. Ручка тотып нәрсәдер шәрехләү практикасы үткәндә калып бара. Каләм ияләре – язучыларның да күбесе бүген хәрефләрне шактый җитез рәвештә клавиатурада җыя, журналистлар шулай ук. Оешмаларда, гомумән, кулдан язылган эш кәгазьләрен көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Хәтта гаризалар да компьютерда җыела. Шуңа һәм шуның ише башка документларга без бик тә эре кыяфәттә, каләм тотып, гадәттә, имзабызны гына салабыз. Тик анысы да бераздан бетәргә мөмкин. «Электрон имза» дигән нәрсә модага кереп маташа.

Ихтимал, эш кәгазьләрен шулай язу дөрес, кирәктер дә. Басма хәреф шул ягы белән уңайлы, аны һәркем таный. Ә кулдан язылганны танып булмаска да мөмкин. Басма хәрефләр урынны да аз ала. Шрифтны да теләгәнчә үзгәртергә – зурны яисә кечерәкне сайларга мөмкин. Басма хәрефләрне кеше генә түгел, компьютер да таный. Һәр хәрефнең 0 һәм 1 саннарыннан торган санлы форматы күптән бар.

Почерк кешенең холык-фигыле хакында сөйли, дидек. Ул гынамы, шул рәвешле адәми затны өйрәнүче графология дип аталган юнәлеш барлыгы да мәгълүм. Аны кайберәүләр хәтта фән буларак та кабул итә. Ничек кенә булмасын, почеркка карап кеше психикасын өйрәнү яши. Кемдер хәрефләрне туры утырта, кемдер артык авыш яза, кемдер лупа аша укырлык вак, икенче берәү «ат башыдай» эре хәрефләр тезә. Кемдер кәгазьгә артыгын баса, кайберәүләрнең нәрсә язганын гомумән дә тану авыр. Артык җәелеп китеп, бер юлга өч-дүрт сүздән артыкны сыйдырмаганнар да юк түгел. Графологлар исәпләвенчә, кешенең баш мие, үзе дә сизмәстән, каләм тоткан кешенең кулына аның ипле яки ипсез булуын, ялкау яисә тырышлыгын, акыл һәм дә сәләт дәрәҗәсен, хәтта рухи дөньясын да чыгара икән. Почеркка карап диагноз ук куймасалар да, кеше затының холык-фигыле белән ул ак кәгазьгә сырлаганнар арасында бәйләнеш чынлап та бардыр. Шунысын да искәртик: почерк, кулдан язылган һәр җөмлә криминалистлар өчен дә бик әһәмиятле. Һәр затның «кулы» башкаларны кабатламау сәбәпле, графологик экспертиза язма авторын төгәл билгели.

Матур язу, дигәндә, тагын бер нечкәлек. Аны каллиграфия дип атарга, шуның белән чагыштырырга да мөмкин кебек. Каллиграфиядә һәр хәреф сәнгатьле, матур гына түгел, үзенчә затлы һәм дә шулар аркасында бөтен кеше дә танырлык итеп тә языла. Почеркы матур кешене, синең язуың каллиграфик, дип мактыйлар. Андый кешеләр гадәттә төгәл, таләпчән, җитди, бөтен эшне дә җиренә җиткереп башкаручылар. Каллиграфия кулланып язылган аерым текстларны сәнгать әсәре дип атау да урынлы кебек. Мәсәлән, гарәп каллиграфиясенә нигезләнеп иҗат ителгән тугралар хәтсез кешеләрнең өй түрендә затлы картиналар белән янәшә тора.

Кулдан язу, хат аша аралау, димәктән, эпистоляр жанр турында да берничә сүз әйтәсе килә. Белүебезчә, әдәби әсәр геройларның бер-берсенә язган хатлары рәвешендә иҗат ителгән икән, жанр шулай атала. Достоевскийның аерым әсәрләре, үзебезнең Гадел Кутуй язган «Тапшырылмаган хатлар», башкасы.

Компьютер һәм гаджетларга күчү, алар аша аралашу шушы гасыр галәмәте булса, кулдан язуның ике-өч мең еллык тарихы бар. Ул тарих кешелекнең башта нәрсәнедер аңлаткан билгеләр, соңрак хәрефләр һәм дә графика уйлап табуына барып терәлә. Аң, белем, мәгълүмат тарату, елъязмалар булдыру, уку-укыту – барысы да язуга, язганны укуга барып тоташа. Кыскасы, кулдан язу кешене кеше итүдә бәяләп бетермәслек роль уйнаган ачыш булып кала.

ХӘЕРЛЕ ЯЛ

Кышкы кәеф

Быелгы буранлы салкын кыш тәмам туйдырган, ахры. Чит илгә юллама сатып алучылар саны 30 процентка арткан. Гыйнвар – февраль айларында кояшлы илләргә барырга теләүчеләрнең бу кадәр күплеген юллама сатучылар да хәтерләми. Ә менә безгә килүчеләр кимергә мөмкин. Көйсез кыш Татарстанны күрергә теләүче туристларны куркыткан. Ял бәясе күпме тора?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшел Үзәндә яшәүче Лилия һәм Марсель Хәкимовлар әле яңа гына Мисырдан әйләнеп кайткан.

– Былтыр диңгез буена ял итәргә барырга җай туры килмәде. Җәй көне эш күп булды, көз көне кызчыгыбыз Әмилә туды. Шуңа күрә кышкы каникулда гаиләбез белән чит илгә барабыз, дип алдан ук сөйләшеп куйдык. Юлламаны көз көне сатып алдык. Дүрт кешегә бер атналык ял 290 мең сумга төште. Хургада шәһәрендә ял иттек. Төннәрен бераз салкынчарак булса да, көндез 28 градус эссе иде. Елның бу вакытында диңгезгә керүчеләр сирәк, балалар җылы бассейннарда рәхәтләнеп коенды. Исәпләп карасаң, бер кешегә бер көнлек ял якынча 10 мең сумга төште. Күп түгел ул. Өйдә азык-төлеккә генә дә атнасына шулкадәр акча тотабыз. Акчаның җитәсе юк аның, ә менә вакытны кире кайтарып булмый, – ди гаилә башлыгы Марсель Хәкимов.

Россия туризм индустриясе берлеге мәгълүматларына караганда, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, Яңа ел каникулларыннан бирле Россиядә чит илгә юллама сатып алучылар саны 30 процентка арткан. Кояшлы илләргә баралар, билгеле. Ял юнәлешләре буенча беренче бишлеккә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Таиланд, Төркия, Мисыр һәм Шри-Ланка эләккән. Алдагы ел белән чагыштырганда юллама бәяләре 50–60 процентка кыйммәтләнде, дип тә өстәгән белгечләр.

Башкаладагы туризм агентлыкларының берсендә юлламалар сату белән шөгыльләнүче Анастасия Егорова әйтүенчә, пандемиягә бәйле чикләүләрдән соң бездән туры юл булган илләр ачылып бетте диярлек.

– Чит илләргә карата кызыксыну арту шуңа да бәйле, – ди ул. – Безгә юллама сорап килүчеләр: «Гел киеренкелектә яшәп арыдык, ял кирәк», – диләр. Моңарчы кышын Европа илләренә сәяхәт итәргә яратучылар шактый булса, хәзер алар да ни чарадан бичара дигәндәй, кояшлы яр буйларын сайлый. Ничек кенә булмасын, февральгә бу кадәр күп юллама сатканны хәтерләмим. Төркия, Мисыр кебек илләрдә бу вакытта диңгезнең салкын булуы да туктатмый. Бәяләр бөтен юнәлешләр буенча да артты. Юлламаның зур өлешен юл чыгымнары алып тора. Былтыр, мәсәлән, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә бер кешегә ике якка билет уртача 30 мең сумнан башланса, быел ул ике тапкыр кыйммәтрәк. Узган ел Төркиягә юлламалар бик нык артты. Биш йолдызлы кайбер кунакханәләрдә ял бәясе 80 процентка кадәр кыйммәтләнде хәтта. Бу җәйдә чит илгә юлламалар 30 процентка кадәр артырга мөмкин дип фаразлана. Шуңа күрә ялны алдан ук кайгыртып куярга киңәш итәбез.

Ә менә Татарстанга килеп җитү кыенлашты. Барысына да көйсез кыш сәбәпче. Бу арада гына да ишеп яуган кар аркасында, федераль юлларда хәрәкәтне ике тапкыр чикләргә туры килде. М12 автомобиль юлы гомумән ябылды. Уфадан очкан бер үк пассажирларны Казан «һава капкасы»ннан ике тапкыр кире борганнар.

– Татарстанга Түбән Новгородтан спорт ярышына дип юлга чыккан җирдән, буран аркасында, кире борылырга мәҗбүр булдык, – ди балалар тренеры Сергей Строков. – Югыйсә сәфәргә алдан ук әзерләнгән идек. Әти-әниләр белән бергә юлга чыктык. Ике куянның койрыгын берьюлы тотып, Казан Кремлен, Черек күлне, Яңа ел чыршы мәйданчыкларын күрү теләге дә бар иде. Балаларның кәефе кырылды. Сәфәрне җәйгә күчердек.

Росстат мәгълүматларына караганда, узган елның тугыз аенда ил буенча сәяхәт итүче туристлар саны – 16, чит илләргә өстенлек бирүчеләр исә 25 процентка арткан. Күпчелек сәфәрләр җәй айларына туры килә. Хәерле юл!

Эльвира ВӘЛИЕВА

ФЕВРАЛЬ АЗАГЫНДА ИКЕ КЕШЕЛЕК ГАИЛӘГӘ ЧИТ ИЛГӘ ИҢ АРЗАН ЮЛЛАМА КҮПМЕ ТОРА?

Ил	Кунакханәнең сыйфаты	Бәясе
Төркия	дүрт йолдызлы кунакханә, иртәнге аш	74 мең (1 атна)
Мисыр	дүрт йолдызлы кунакханә, ашау-эчү кергән	116 мең (1 атна)
БГӘ	дүрт йолдызлы кунакханә, иртәнге аш	126 мең (1 атна)
Таиланд	өч йолдызлы кунакханә, иртәнге аш	273 мең (10 көн)
Шри-Ланка	өч йолдызлы кунакханә, иртәнге аш	204 мең (11 көн)

Бәяләр tourvisor.ru сайтыннан алынды.

Без бел(мә)гән тарих

ҖӘБӘЛИ АТЛЫ МӘГЪРИФӘТЧЕ

Яшел Үзән районындагы Бәчек авылы кечкенә генә булса да, тарихы зур булып чыкты. Кайчандыр бөек Тукаебызның апасы Саҗидә кызы белән шушында яшәгән. Өммехания апа башлангыч мәктәптә укыткан. Авыл кешеләре аларның каберләрен кадерләп карап торалар. Соңгы вакытта тагын бер зур яңалык: Бәчек авылында имам булып эшләгән Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улы әл-Җәбәлинең кулъязмасы, китап булып, халык хозурына тапшырылды.

Бу – XIX гасыр укымышлылары Ибраһим Хәлфин, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсән Фәезханов, Каюм Насыйри янәшәсенә тагын бер исем өстәлде дигән сүз. Шунысын да искәртү урынлы булыр: Минһаҗетдин хәзрәт бу хезмәтен язган вакытта татар тарихы буенча үз телебездә фәнни хезмәтләр басылып чыкмаган булган әле. Димәк, ул беренче дип фаразларга нигез бар.

Ничек мәгълүм булды?

Минһаҗетдин Җәбәли тарихи хезмәт язуга җөрьәт иткән, әмма төрле сәбәпләр белән әсәре дөнья күрми калган. Бу хакта мәгърифәтченең «Тәварихы Болгарийә вә татарийә» кулъязма җыентыгын басмага әзерләгән тарихчы Раиф Мәрданов болай дип сөйли. «Элек Минһаҗетдин Җәбәли җыентыгы археограф галимә, педагог Зәйнәп Максудова карамагында булган. Ул аны кайдан кулга төшергәндер – билгеле түгел. Җыентыкны 1962 елда Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсенә тапшырган. Кулъязма хәзерге вакытта сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана. Аның белән галимнәр кызыксынганлыгы мәгълүм. Әмма җыентыкның каралама хәлендә булганлыгы, тексты тулы түгеллеге һәм битләре буталганлыгы сәбәпледер – аны тикшереп, нәшер итәргә омтылучылар һәм мәкалә язучылар билгеле түгел. Минһаҗетдин Җәбәлинең хезмәте, гомумән, фән дөньясында һаман да билгесез иде».

Кем ул Җәбәли?

Тарихи әсәр язган Минһаҗетдин Сәйфулла улы – үзе белдергәнчә, Яшел Үзән районының Мамадыш авылына нисбәтле нәсел вәкиле. «Җәбәли» дигән нисбәсе гарәп телендәге «җәбәл» – тау дигән сүздән алынган һәм Идел елгасының уң тарафы – Тау ягы кешесе икәнен белдергән. Нәселләрендә «бабайлар унике кеше имам булып үткәннәр» дип искәрткән. Аның Бәчек зиратындагы кабер ташына «мулла Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улы» дип язылганына караганда, әтисе дә имам булуы аңлашыла. Мәгърифәтче галим Каюм Насыйри да бер мәкаләсендә үз әтисенең 1857 елда Бәчек авылы мулласы Сәйфулла хәзрәт белән әңгәмәсен искә алган. Ул нәкъ менә Минһаҗетдинның әтисе булган. Димәк, төп нәсел тамырлары Мамадыш авылына бәйләнгән Минһаҗетдинга кадәрле үк аның әтисе Бәчек авылында имам вазыйфасын үтәгән. Зөя өязендәге Мамадыш-Әкил авылының 1850 елгы халык исәбен теркәү документында Сәйфулланың да гаилә әгъзалары теркәлгән. Анда Минһаҗетдин исемле улының 1838 елның 19 июнь көнендә туган булуы язылган. Минһаҗетдин Җәбәли Түнтәр авылында (хәзерге Балтач районында) данлыклы Гали ишан мәдрәсәсендә укыганлыгын һәм остазыннан Бәчек авылында имамлык итәргә рөхсәт-фатиха алганлыгын да язган.

Минһаҗетдин Җәбәлинең кабер ташы.

Минһаҗетдин Сәйфулла улының тарихны мөкиббән китеп өйрәнүенә остазы Гали ишанның да йогынтысы булгандыр дип уйларга кирәк. Тарихчы Ризаэддин Фәхретдиннең Гали ишанның иң булдыклы 14 шәкерте арасында Минһаҗетдин Җәбәли исемен күрсәтүе дә очраклы түгелдер. «Бу шәхеснең тормыш юлы һәм гыйльми мирасы киләчәктә галимнәр һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр тарафыннан җентекләп тикшерүгә лаек, – ди бу җәһәттән Раиф Мәрданов. – Үзе дә мәдрәсәдә белем алган һәм укыту эше белән шөгыльләнгән кеше буларак, татарларда уку тәртибе турында ул язып калдырган мәгълүмат мәгариф һәм педагогика тарихыбыз өчен – шулай ук кыйммәтле ядкәр. Җыентыкта иске кабер ташларыннан, тел-сөйләм мисалларыннан, географик атамалардан, дини һәм фәнни китаплардан күчерелгән мәгълүматлар тупланган. Автор халык аваз иҗатына да мөрәҗәгать иткән. Борынгы төрки-татарларның төп ватаннары, килеп чыгулары, яшәгән һәм биләгән урыннары, ислам динен кабул итүләре тарихына зур әһәмият биргән. Идел буенда яшәгән чуашларның һәм фин-угор халыкларының татарларга якын нәселдәш тармаклар икәнлеген һәм барысының да әүвәл мөселман булып, Казан ханлыгы басып-яулап алынганнан соң гына мәҗүсилеккә төшкәннәрен язган».

Изгеләр каберлеге

Бәчек авылы гына түгел, барлык татар өчен Минһаҗетдин Җәбәли исемле милләттәшебез булу – яңалык та, зур горурлык та. Мәгърифәтченең кабер ташында аның 1893 елның 7 декабрендә, 54 яшендә вафат булганлыгы, 30 ел имам булып торганлыгы язылган. Ташъязмадагы мәгълүматка караганда, Минһаҗетдин Сәйфулла улы 1863 елдан алып Бәчек авылында имам вазыйфасын башкарган. Хәзрәтнең кабере янында шундый ук шәкелдәге ташъязмада аның җәмәгате Ләйләҗамал Габделгалим мәзин кызының исеме уелган. Ул ел ярымга иреннән алдарак дөнья куйган. Тарихчы мулла Минһаҗетдин Җәбәли вафат булганнан соң Бәчек авылында аның улы Мөхәммәтпарса имамлык иткән. Ул 1871 елда туган. Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укыган. 1894 елда совет чорына кадәр мулла булып торган. Бәчек авылы халкы әйтүенчә, 1930 нчы елларда кулак итеп хөкемгә тартылган.

Бәчек авылында мәчет – бүген дә халыкны берләштереп торган бердәнбер урын. Беренчедән, ул – тарихи бина, монда Саҗидә апаның кызы Өммехания апа укыткан. Икенчедән, авыл халкы үз инициативасы белән экспонатлар җыеп, музей эшләп куйган. Авылда 120ләп кеше яши, 70ләп төтен бар.

Берьюлы ике вазыйфа алып баручы – җирле үзидарә башлыгы һәм Бәчек авылы имамы Хәйдәр Сибгатуллин белән соңгы вакыйгалар турында гәпләшеп алдык.

– Зираттагы борынгы ташларны белә, күрә идек, – ди ул. – Безнең әбиләребез, бабаларыбыз аларны «изгеләр каберлеге» дип атап, дога укырга йөрделәр. Без дә бу гореф-гадәтне дәвам итәбез. Тик, ничектер, анда җирләнгән кешеләрнең кем икәнлекләре турында сөйләшүләрне хәтерләмим. Кабер ташындагы хәрефләр нефтьне манчып язылган булса кирәк, ни гаҗәп, урыны-урыны белән кара төсләре бүгенгә кадәр җуелмаган.

Әйтергә кирәк, бу зур эшнең башында тарихчы Ирек Һадиев тора. Ул, бер кайтканда, кабер ташларында ниләр язылганын укып киткән иде. Аннан кулъязма тарихы турында хәбәр ирештерде. Бу безнең өчен бик сөенечле вакыйга булды. Ничек булса да, якташыбызның исемен мәңгеләштерергә иде. Кулыбыздан килгәнне эшләү дигәндә, беренче чиратта мәчетебездә бер почмак ясап куярга исәплибез. Быел Бәчек авылына нигез салынуга 810 ел була. Аны да, тарихчыларны чакырып, истәлекле бәйрәм итеп үткәрәсе килә. Тукайның апалары турында да, Минһаҗетдин Җәбәли турында да кайтып-кайтып сөйләргә, милләттәшләребезгә җиткерергә кирәк дигән фикердә без. Әлегә якташыбызның нинди бөек кеше икәнлеген авыл халкы да аңлап бетерми кебек.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯҢА ДУЛКЫН

Әдәби бәйге

Әдәбиятка җан өрде, язучыларны «уятып» җибәрде. Киң җәмәгатьчелек арасында шактый кызыксыну тудырган ябык әдәби конкурс турында шулай дияргә яраталар. Быел аның икенчесе үз нәтиҗәләрен күрсәтәчәк, конкурста җиңгән әсәрләр укучыга барып җитәчәк. Әлегә жюри әгъзалары һәм җиңүчеләр белән сөйләшик. Конкурстан канәгатьме алар? Конкурс бүгенге әдәбиятка нинди «диагноз» куярга ярдәм иткән?

Көтмәгәндә, уйламаганда...

Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә үткәрелгән конкурсның тугыз номинациясендә җиңүчеләрнең исемнәре язылган конвертлар инде ачылды. «Роман» номинациясендә җиңгән авторларны февраль аенда беләчәкбез. Романнар инде бер кат укылып чыккан. Димәк, конкурска тулы бәя бирергә була.

Сыйфат һәм эчтәлек турында сөйләшүгә күчкәнче, саннарга күз салыйк. Конкурска 1641 эш килгән. Чагыштыру өчен: беренче конкурста 1470 эш кабул иткән булганнар. Оештыручылар һәм жюри әгъзалары мондый нәтиҗә көтмәгән дә. Конкурс комиссиясе әгъзасы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин шулай ди.

– Яңалык булгач, беренчесендә күп катнаштылар, бу юлы кимрәк булыр инде дип уйлаган идек. Ләкин килгән эшләр саны без уйлаганнан да артыграк булды. Сыйфатка килгәндә, жюри әгъзалары бигрәк тә проза әсәрләрен югары бәяләде, тема ягыннан төрлелеккә игътибар иттеләр, – дип сөйләде ул безгә.

Ә поэзиягә килгәндә, быел поэмалар белән шигырьләрне берләштергән булганнар. Поэмалар күп булмас дигән фараз белән эшләнгән ул.

– Ләкин поэмалар да, шигырьләр дә шулкадәр күп килде ки, жюри әгъзаларына өч урын билгеләү шактый кыен булды, – диде Рөстәм Галиуллин.

Конкурста җиңүчеләрнең әсәрләре «Казан утлары»нда басыла. Беренче конкурстан соң журнал укучыларыннан шактый яхшы кайтавазлар килгән.

– Журнал өчен шактый яңа исемнәр дә ачтык. Без бит җиңүчеләрнең генә түгел, башка катнашучыларның да әсәрләрен бастырдык. 30–40 яшьләр тирәсендәге моңарчы безгә таныш булмаган шактый авторлар табылды. Алга таба да аларның иҗатын күрербез дип ышанам, – диде Рөстәм Галиуллин.

Яңа исемнәр

Жюри әгъзаларының берсе, Татарстанның халык шагыйре Газинур Моратның да быелгы бәйге турындагы фикерен белештек. «Әйбер күп булгач, сайлап алу да рәхәтрәк», – ди ул.

– Сан сыйфатка әйләнә дигән кагыйдә бар бит. Бу очракта да конкурска килгән эшләр санының ишәюе – һичшиксез, уңай күренеш. Романнар гына да 23 булган бит! Әдәби процессны «яндырып» җибәрү, язучыларның күңелен күтәрү ягыннан гына карасаң да, бу конкурсның әһәмияте зур. Ул дәвам итәргә тиеш, – дип сөйләде ул безгә.

Конкурсның тагын бер әһәмиятле ягы – яңа исемнәр барлыкка килү. Газинур Морат сүзләре белән әйтсәк, бер үк язучылар гына катнашып, бер үк кешеләр генә җиңеп торса, ул кадәр файдасы булмас иде.

– Беренче тапкыр уздырылган конкурста «Проза» номинациясендәге эшләрне укыдым. Ул чакта Наилә Харисова исемле ханым гаҗәпкә калдырган иде. Быел миңа шигъри әсәрләр укырга туры килде. Шулай ук моңарчы ишетелмәгән авторлар шактый очрады. Әйтик, Гөлсәрия Басыйрова исемле ханым II урынга лаек булды. Гомумән, әсәрләрне укыганда шулкадәр профессиональ язылганнары очрый да, җитлеккән язучыдыр инде бу, дип уйлап куясың. Баксаң, ул синең өчен бөтенләй яңа исем була. Мондый авторлар килеп чыга икән, димәк, конкурс үз максатына ирешә, – дип сөйләде шагыйрь.

Шигъриятебез исәнме?

Шулай ук шигъри әсәрләрне бәяләгән жюри әгъзасы, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров та конкурска килгән эшләрдән бик разый калган.

– Миңа 100гә якын шигъри әсәр укырга туры килде. Бер карасаң, бик катлаулы эш. Әмма, икенче яктан, бу әсәрләрне укып чыккач, зур канәгатьләнү хисе кичердем. Чөнки минем алдымда бүгенге шигърият панорамасы ачылып киткәндәй булды. Ул исәнме? Үсештәме? Шагыйрьләребезне нинди проблемалар кызыксындыра? Безнең әдәби телебез ни хәлдә? Шушы сорауларга җавап таптым. Һәм, дөресен әйткәндә, уңай җавап алдым, – ди ул. – Билгеле, сүз боткасына тартым булган, сүзләр җыелмасыннан торган шигырьләр дә, хикмәте, милләт гаме булмаган әсәрләр дә очрады. Ләкин бу – табигый хәл. Гомумән алганда, бүген шигърият үсештә дип уйлыйм.

«Татар-информ»

Барлык җиңүчеләр дә 21 февраль – Халыкара туган тел көнендә тантаналы чарада бүләкләнәчәк.

Тарих, тамырлар, үткәннәр, милләт. Конкурстан чыгып кына нәтиҗә ясасаң, бүгенге шигърият һәм шагыйрьләр – әнә шул дулкында.

– Тарихи тема, үткәннәргә караш, тамырларыбызның тирән булуына ишарә бигрәк тә поэмаларда күзәтелә. Безнең шигъриятне элек-электән борчыган мәсьәләләр бүген дә актуаль. Милләт темасы, аның яралары, тел язмышы, киләчәк турында уйланулар шулай ук еш очрады, – дип сөйләде Зиннур Мансуров.

Бала күңеле...

Балалар шигъриятенә дә бәя биргән жюри әгъзасы булгач, Зиннур әфәнде белән балалар һәм үсмерләр әдәбияты турында да сөйләшми булдыра алмадык. Әлеге бәйге әдәбиятыбызның бу катламындагы «бушлык»ны тутыра алырмы?

– Балалар өчен язылган әсәрләр сөендерде. Кайбер авторларның педагогик белеме булуы да сиздерә. Бала күңелен аңлап язылган, балаларны җәлеп итә торган әсәрләр укырга насыйп булды. Без балалар һәм үсмерләр әдәбияты җәһәтеннән канәгатьсезлек хисе белдерергә яратабыз инде. Әйтик, шул ук совет чорында балалар өчен язучы авторлар күбрәк иде. Өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә язу традициясе бар иде. Бүген бу традиция дә югала. Ләкин конкурска килгән әсәрләр буенча гына нинди дә булса нәтиҗә чыгару дөрес булмас. Конкурста катнашмаган әдипләребез дә бар бит. Әмма шунысы хак: бу чара әдәбияттагы тенденцияләрне, яңа «чир»ләрне ачыкларга бик ярдәм итә, – дип җавап бирде Зиннур Мансуров.

«Повестьны башлаганда ук балалар, үсмерләр өчен дип тәгаенләгән идем, андый әсәрләргә кытлык икәнен яхшы беләм», – ди «Повесть (үсмерләр әдәбияты)» номинациясендә I урынга лаек булган Айгөл Әхмәтгалиева. Чаллыда яшәп иҗат итүче язучының тагын бер әсәре «Поэма яки шигырьләр шәлкеме (балалар һәм үсмерләр әдәбияты)» номинациясендә II урынны алды.

– Күптән бер җиңел рухтагы, балалар да, олылар да рәхәт бер җылылык белән укый торган әсәр язасым килә иде. Максатыма ирештемме икән – анысын укучылар әйтер инде, – ди ул «Без андый малай түгел» повесте турында. – Балалар, бигрәк тә үсмерләр өчен иҗат итү бик авыр. Үз җаның алар җаны белән бәйләнмәсә, аларны ни борчыганын аңламасаң, язым әле, дип кенә ясалма әйбер тудырудан ни мәгънә? Минем үземне менә шушы әйбер һәрчак чабудан тартып тора. Бервакыт язучылар съездында шул елдагы балалар әдәбияты турында доклад әзерләүне миңа тапшырганнар иде. Ай буе алдымда китаплар, газета-журналлар өелеп торды, кат-кат укып, бермәлне хәтта күз яше белән елап алдым. Балалар өчен сыйфатлы, чын әсәр дигәннәрен бармак белән генә санарлык сайлый алдым да үземне артык таләпчәнлектә битәрләп игәүләдем. Шул чактагы төп ачышым – балалар һәм үсмерләр өчен язганда язучының ихлас булуы, ясалмалыктан качуы һәм үгет-нәсыйхәт бирмәве мөһим икән. Ә бу исә бер дә җиңел түгел...

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Мәдәният дөньясында

ЯШЬЛӘРГӘ САБАК

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫ ЕЛНЫ НИНДИ ПРЕМЬЕРАЛАР БЕЛӘН БАШЛЫЙ?

Кәрим Тинчурин театры узган елны нинди нәтиҗәләр белән тәгәлләгән? Яңа елда безне нинди яңалыклар һәм премьералар белән гаҗәпләндермәкче? Матбугат очрашуында әнә шулар хакында сөйләделәр.

Тинчурин театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов узган 2023 елны театр өчен уңышлы дип атады.

– 355 спектакль куйганбыз. Кайбер көннәрне өчәр җирдә спектакль куелганы булды. 90 меңнән артык тамашачы булган. Гастрольләргә күп йөрелде. 45 миллион сумнан артык акча эшләнгән. Чагыштыру өчен: 2019 елда керем 17 миллион сум гына иде. Ә узган елга караганда быел 10 миллионга күбрәк эшләгәнбез. Ул яктан уңышлы ел булды, – диде ул. – Беренче яртыеллыкка әзерлек эшләре күптән бара. 25 гыйнварда «Синең хакта» дигән театральләштерелгән концерт була. Ул татар театры тарихына багышланган. Быел – Гаилә елы. Шул уңайдан гаилә абонементы булдырдык. Гаилә әгъзалары бергә билет алсалар, 30 процент ташлама ясалачак.

6–7 мартта Тинчурин театрының Мәскәүгә гастроле көтелә. Фәнис Мөсәгыйтов әйтүенчә, аларның теләге зур шәһәрләргә, уңайлы җирләргә генә йөрү түгел.

– Ераграк районнардагы авыллар да бар, алар «Пушкин картасы»н бер җирдә дә куллана алмый. Кайберләре беркая да чыга алмый. Бер тапкыр районга барып кайтсалар да шатланалар. Шушындый авылларга якынрак булган мәдәният йортларын алып, кечкенә авыллардан җыярга тырышабыз. Алар елына берме-икеме тапкыр булса да профессиональ спектакль карарга тиеш. Җайсыз булса да, барырга тырышабыз. Андый авылларның исемлеге бар, һәрберсе белән элемтәгә кердек, ел дәвамында алар белән эшләячәкбез, – дип сөйләде директор.

tinchurinteatr.ru

Ел башында театрда ике премьера көтелә. 31 гыйнвар һәм 1 февральдә Г. Исхакый әсәре буенча «Җан Баевич» трагикомедиясе куелачак. Режиссеры – Илнур Гарифуллин.

– Безгә «Пушкин картасы» белән яшьләр карарлык спектакльләр дә кирәк. «Җан Баевич» мәктәп программасында бар, темасы да кызыклы. Без һаман чит милләтләргә, чит илләргә охшарга тырышабыз. Аларны кабатлап, гореф-гадәтләрне, телебезне югалтсак, нинди көлке хәлгә калырбыз – шуны күрсәтәсе килә, – диде театрның баш режиссеры Туфан Имаметдинов.

Бер гасыр элек яшәгән татар бае ролендә – Татарстанның атказанган артисты Зөлфәт Закиров.

– Күпләр бу образга симез, зур гәүдәле артист, әйтик, Рөстәм Гайзуллин күбрәк туры килә, дип әйтергә мөмкин. Тик замана тиз алышына. Хәзер бу образда җиңеллек булырга тиеш. Илнур, кистереп: «Бу рольдә мин сине генә күрәм», – диде, – дип уртаклашты Зөлфәт Закиров. – Режиссер белән әсәрне укып чыккач, монда бит хәзерге заман проблемалары күтәрелгән, дигән фикергә килдек. Миңа калса, әсәр яшьләребезгә кызык та, шул ук вакытта гыйбрәт тә булыр. Бүгенге яшьләрнең интернетта әллә нәрсәләр карап, 5 секунд эчендә әллә кем буласылары килә. Әсәрдә дә шул зур проблема чагыла.

20–22 февральдә театр икенче яңа спектакль – «Флешка, рэп һәм мәхәббәт» дип аталган хип-хопера тәкъдим итәчәк. Авторы – Илгиз Зәйни. Режиссеры – Туфан Имаметдинов.

– Илгиз Зәйниевнең безнең өчен язган әсәре. «Иттифак» рэп төркеменең беренче альбомына кергән һәм әлегә кадәр дөнья күрмәгән җырларыннан бер спектакль төзибез. Бүген бернәрсә эшләмичә, тиз генә видео төшереп, байыйсылары, популярлык казанасылары килгән кешеләр шактый. Бу тема бик актуаль. Спектакль күбесенчә студентлар өчен. Безнең тамашачы төрле, әмма яшьләргә кагылган темаларны да ачарга телибез, – диде баш режиссер.

Сүз уңаеннан, Тинчурин театры коллективы тагын да ишәйгән. Театр труппасына Казан театр училищесында Зөлфәт Закиров курсын тәмамлаган Ильвина Кәримованы алганнар. Яшь актриса Биектау районының Дөбьяз авылыннан икән.

Театрда кадрлар мәсьәләсе – аерым проблема.

– Театрда урыннар күбрәк булса, яшьләр килер иде. Бу проблема бездә генә түгел, Кариев театрында да, Камалда да, гомумән, бөтен Россия театрларында. Бу – бик катлаулы мәсьәлә, – диде остаз.

Быел театрның 90 нчы сезоны гына түгел, оркестрның да 35 еллыгы. 28 февральдә театрда оркестрның юбилей концерты узачак.

– Яңартылган оркестр составы эшли башлавына да биш ел булды. 35 елга да, соңгы бишьеллыкка да нәтиҗәләр ясалачак. Юбилей елы кысасында берничә аудиоальбом яздырырга ниятлибез. Анда композитор Салих Сәйдәшевнең драматург Кәрим Тинчурин белән бергә иҗат иткән әсәрләре дә керәчәк. 90 еллык театр тарихында эз калдырган спектакльдән фрагментлар, җырлар булачак, – диде театр оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры Ильяс Камалов.

Ләйсән САФИНА

Шигърият

__Гөлсәрия БАСЫЙРОВА__ Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе ярдәме белән үткәрелгән әдәби конкурста «Поэма яки шигырьләр шәлкеме» номинациясендә беренче урынны алды. Чыгышы белән ул – Пермь краеның Барда районы Бардабаш авылыннан. Чаллы шәһәрендә «Таң йолдызы», «Ислам нуры» газеталарында, Өзлексез педагогик белем бирү институтында эшләгән. 2018 елдан шигырьләр яза.

* * *

Кылган төсле чәчләремне
Искән җылы җил тарый.
Кылган диеп белде мәллә,
Тарасын, әйдә, ярый.

Үзем дә җилгә ияреп
Очам дала ягына.
Хыялый уйларым чөнки
Иркенлекне сагына.

Искән җилдән калмас идем,
Сагынып кешем булмаса.
Юл чатында моңлы бер җан
Кулын изәп тормаса...

КӨЙ...

Дулкындай агылып киләсең...
Туктама, мин сиңа иярдем.
Иңрәүдән кылларым тартылса,
«Түзәлмим... Аh! Тукта...» – диярмен.

Ишетәм ярсулы авазың,
Мин бүген нәкъ шундый халәттә.
Иярдем берсүзсез, ирексез,
Хисләрне тыйсам да гадәттә.

Дулкының күтәрде биеккә,
Өермә ясадың күңелдә.
Ләззәтең шундый да сихерле,
Әйләндем мин көйгә үзем дә...

* * *

Кайвакытта адашу да кирәк...
Кармаланып бару караңгыда...
Аңлар өчен яктылыкка чыккач:
Кемнәрең бар... Кемнәр үз яныңда?..

Аңлар өчен яшәү кадерләрен,
Тормышыңның – якты көннең ямен.
Югалтмыйча калып, саклый алган
Аңлар өчен тамчы сөю тәмен.

Азга гына адашу да кирәк,
Саташу да кирәк кайчагында.
Үз-үземне бары югалтмыймчы,
Калебемдә җаным бар чагында...

БАРЫБЕР ТАБАР ИДЕМ

Чишмә булсам, аның кебек
Гел җырлап агар идем.
Сиңа илтәсе юлларны
Барыбер табар идем.

Төнге күктә йолдыз булсаң –
Гел күккә багар идем.
Нурыңнан синең яктыны
Барыбер табар идем.

Кышның бозы булсам да мин,
Барыбер янар идем.
Сине дә яндырыр өчен
Әмәлләр табар идем...

ӨМЕТ ТӨСЕ

Хыялларның җетелеге уңды,
Якты төсләр никтер югалды.
Агы ак та, ә карасы кара,
Иртәләрем шундый томанлы...
Ерып бара җаным шул томанны,
Яктырасын белеп уйларның.
Вакытлыча, бар да вакытлыча –
Хыялларны төскә буярмын.
Рәссам җаным буяуларны өстәр,
Әле алын, әле сарысын.
Өмет төсен генә онытмасын,
Ул үзгәртер тагын барысын...

* * *

Бу тынгысыз уйны тыялмадым –
Йөгереп чыкты төнге урамга,
Әллә ниләр табар кебек булып,
Бөтерелгән ап-ак буранда.
Буран бит ул ярсу гына өсти
Тынычлыгын җуйган хәяткә.
Уйларыма сихәт килсен өчен,
Җәйләр кирәк миңа, әлбәттә.
Кыңгыраулар үскән болын кирәк,
Таралуы җиләк исенең...
Әй бу уйлар, җанын алгысытып,
Кайда гына йөртми кешене.
Тынар өчен яратуын эзли,
Хисләренә күнеп, аптырап.
Арып-талып дөнья гизеп кайта...
...Анда инде таң да яктыра.

* * *

Әйтерсең лә соңгы языммыни,
Үрсәләнеп көтәм аны быел.
Алгысыма, күңел, язлар килер...
Тыел инде әзрәк, син бер тыел!

Ярсып аккан кар сулары белән
Агалмадың әнә диңгезләргә.
Кире кайтмаслыгын беләсең ич,
Үткән яшьлегеңне ник эзләргә?

Барыбер мин язны өзелеп көтәм,
Бөреләрнең көтәм уянуын...
Түземлегем бетеп, ашыкканга,
Соңгысымы, диеп уйлануым...

Тик соңгысы түгел. Түгел... Түгел...
(Картаюны белми тиле күңел!)

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Карлы көн (Snow day)

Кар да кар… Бүген дөньяның
Аклыкка туйган чагы…
Котылудан мәгънә бармы,
Көрт күмсә каланчаңны?

Сукранулы, сокланулы
Кар белән изгән-баскан…
Бер гомердә ничә буран
Үтелгән икән баштан?

Кар да кар… Бүген дөньяның
Аклыктан туйган чагы…
Ак буранны сылтау итеп,
Акылын җуйган чагы…

Гөлүсә БАТТАЛОВА

Гөнаһларым булмагандыр

Сугыш башланганда миңа 4 яшь тә 9 ай булган. Апама – 7 яшь, сеңлемә – 1 яшь тә 52 көн, әтиемә – 34, әниемә – 31 яшь. Әтиәни дә, балачак еллары да, онытылмаслык итеп күңелләргә сеңеп калган өзелеп ашыйсы килү, шуны оныту өчен тончыга-тончыга, күзләрдән, борыннан яшь, тозлы су агу истә, һаман да истә әле.

Тәмәке тартырга да өйрәндем мин. 11 яшемдә оста тәмәкече идем. Өйрәнергә зурлар булышты: тәмәкесез итмәделәр. Заманы болгавыр булгач, әни дә тыймады, тавышланмады. 1944 елда ул сыер савудан дуңгыз фермасына күчте. Шул вакыттан колхозны бетергәнче мин аның уң кулы булдым. Җир кардан ачылуга, көзгә кадәр дуңгызлар минем карамакта иде. Ул заманның Мауглие булганмын инде мин. Ялгыз гына булганга, көн буе алар белән сөйләшә, хәлләрен сораша идем. Кәефләре яхшы булса, башларын күтәреп, кыска-кыска гына ых-ых дип, миңа карыйлар иде. Кәефе начары яныма килеп, елаган кебек, сузып кына нечкә тавыш чыгара иде. Андыйларның аркаларыннан кагып, аңлаганымны белгертә идем.

Ике-өч «адъютант»ым да бар иде. Аларга атланып та йөрим. Аларга кызык, миңа рәхәт. Тобага су коеныгра төшәбез. Өсләренә утырып (аякларны бөкләп) йөзәбез. Тәмәкегә килгәндә исә, ике кесәм тулы, бакчада үстерәбез. Ике түтәл, ике сорт – саксонский, турецкий. Дөрес, тәмәкене апам үстерә. Су сибәргә дә, утарга да кирәк бит, кәгазьгә төрерлек итү өчен эше күп әле аның. Барысын да язсам, кечкенә китап булырлык. Бергә яшәгәч, чучкалар да миңа мәрхәмәтле иделәр. Үзләренә дип пешерелгән бәрәңгедән, аертылган сөттән өлеш калдырдылар. Сирәк кенә булса да, көрпәле оннан әни кабартма да пешереп бирә иде. Хайван ризыгын урлау, ашау зур гөнаһ икәнен бала чактан беләм. Күрәсең, бу очракта минем гөнаһларым булмагандыр. Ходай үзенең рәхмәте белән кичергәндер. Гөнаһлы булсам, гомер юлларымда искә төшерер иде. Бүгенге көнем, тормышым өчен Ходайга башымны иям.

Бала чактагы хатирәләр сандыгын бушату өчен, китаплар язу кирәк. Сандыктагы истәлекләрне шигырь итеп тә язам.

Сугыш чоры балалары

Сугыш чоры балалары
Наз күрмәгән.
Күзләреннән гомер буе
Яшь китмәгән.
Сугыш чоры балалары
Сабан сөргән.
Таңнан торып, билен буып,
Үгез җиккән.
Сугыш чоры балалары
Зарланмаган.
Зурлар йөген иңнәрендә
Алып барган.
Сугыш чоры балалары
Нинди булган?
Иң яшенә бүген инде
Сиксән тулган.
Сугыш чоры балалары
Сагыш-моңлы.
Йөзләренә ягылып калган
Сугыш чоры.

Шәүкәт КАМАЛОВ.
Алексеевск районы

ЗИРӘК УРМАНЧЫ

Балык Бистәсе районының Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгына 34 ел гомерен багышлаган РСФСРның һәм Татарстан АССРның атказанган урманчысы Тимерхан Габделхаковны искә алу чарасы узды.

Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгына шактый танылган шәхесләребезнең язмышы бәйле. Үз вакытында биредә Россиянең һәм Татарстанның атказанган урманчысы Нургали ага Миңнеханов хезмәт куйды. Әтиләре монда эшләгәндә, аның өч улы: Рифкать, Рөстәм һәм Рәис дөньяга килде. Алар да – республикабызда үзләрен таныткан билгеле шәхесләр.

Эшне Кызыл Йолдыз урманчылыгы җитәкчесе Нияз Тәҗмиев белән шул чорда эшләгән ветераннарны барлаудан башладык. Чакыру җибәрдек. Аларны үзебезнең арада күреп сөендек. Кызганыч, шактый ветераннарыбыз инде бакыйлыкка күчкән.

Тимерхан Габделхак улына быел декабрь аенда 95 яшь тулган булыр иде. Искә алу чарасы Ямаш авылында башланып китте. Башта каберен зиярәт кылдык. Аның җәсәде хатыны Камал Хәйрулла кызы белән янәшә куелган. Ул да гомер буе Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгында хисапчы булып эшләде. Алыштыргысыз белгеч, үз эшенең остасы иде. Авыл мулласы мәрхүмнәрнең рухына Коръән укыды. Икесенең дә каберенә чәчәкләр салдык.

Аннан соң Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгына кайтып, үзебез эшләгән бүлмәләрне карап йөрдек. Тимерхан Габделхак улы кабинетына да кердек. Юк икәнен дә беләбез. Керми китсәк, хәлен белми китәрбез кук иде. Монда шул ук тәртип, пөхтәлек… Аның белән бергә йөргән коридорлардан уздык. Күңелдә хатирәләр дулкыны кузгалды.

Кукмара якларыннан килеп, безнең Балык Бистәсен үз итеп, яратып яшәде Тимерхан Габделхак улы. Кызыл Йолдыз бистәсен чәчәкләргә күмде, халыкка уңайлы яшәү шартлары тудырды, эшчеләрнең мәнфәгатен кайгыртты. Эшчеләрнең хезмәт хакын арттыруга мөмкинлекләр тудырды. Хәтта йорт саен халыкка җиләк-җимеш агачлары кайтартып таратты.

– Бакчаларыгызга утыртыгыз! Җимеш бирә башлагач, аңларсыз. Бакчасында алма үскән яшь-җилкенчәк, чит кеше бакчасына кереп, алма урлаудан туктар, – диде ул.

Урман хуҗалыгында яшьләр күп булганлыктан, күңелле, актив яшәдек. Бистә гөрләп торды. Бәйрәм саен концертлар, спектакльләр куя, ел саен Сабантуйлар уздыра идек. Тимерхан Габделхак улы күп башлангычларга юнәлеш биреп торды.

Урманнарны саклау, аларның үрчемен арттыру, урман хуҗалыгының продуктлылыгын күтәрү һәрвакыт Тимерхан Габделхак улының күз уңында булды. Аның җитәкчелегендә урман хуҗалыгы җитештерү базасы булдырылды, агач материалларын, агач калдыкларын рациональ куллану, агач эшкәртү җайга салынды. Урман хуҗалыгының киләчәген уйлап, анда эшләргә кадрлар әзерләү мәсьәләсен, аларга белем бирү кирәклеген дә алдан ук уйлап эш итте. Үзе үстергән белгечләрне оясыннан җибәрә, яңа үрләргә рухландыра да белде. Күп кенә урманчыларга хыялларын тормышка ашырырга булышты. Мин дә аның хәерфатихасы белән Казан шәһәр яны урман хуҗалыгына эшкә күчендем.

Еллар узган саен, аның ни дәрәҗәдә акыллы һәм алдан күрә белүче урманчы булуына ныграк инана барам.

Бервакыт шулай күп итеп чыршы, нарат агачлары утырттык. Тимерхан Габделхакович, юк-бар агач утыртабыз, дип борчыла. Имәннәр ел да орлык бирә алмаганга, имәнлекләр үрчемәгәнгә сызлана иде. Бу агачка өстенлек бирергә кирәклеген гел искәртә килде. Табигать имән, юкә, өрәңге, чикләвек, элмә агачларын көтеп, җирсеп яшәде. Глобаль җылыну процессы көчәя башлагач, теге вакытта утырткан чыршы-наратларыбыз үз функцияләрен үти алмас хәлдә калдылар. Моның шулай буласын әллә кайчан аңлаган булган зирәк урманчы.

Кызлары Равия һәм Роза ханым шулай ук әти-әниләре турында күңел хатирәләрен кузгаттылар. Мул табыннар әзерләп, искә алу чарасын оештыручыларга рәхмәт хисләрен белдерделәр. Хәтер чарасында катнашкан һәркем бу теләкләргә кушылды.

Харис МУСИН,
Россиянең һәм Татарстанның атказанган урманчысы

ТУГАН ЯКТАН ИЛҺАМ АЛЫП

Һәр төбәкнең горурланырлык шәхесләре бар. Менделеевск районы Камай авылы да талантларга бай. Монда Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина, шагыйрь, журналист Дифгать Сирай, Татарстанның атказанган артисты Рәмзия Зиннәтуллина, шагыйрь Камил Гыйльмуллин, Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры артистлары Ринат Юзикеев һәм Мәйсәрә Нурмөхәммәтова туып-үскән. Алар иҗатлары белән туган ягыбыз данын еракларга таратканнар.

Авылдашыбыз Дифгать Сирай егерме елдан артык иҗат чорында «Таң сызыла», «Саумы, тормыш!», «Кушнарат», «Кыяларга үзем менәм», «Кеше турында җыр» һәм «Мәхәббәтем» исемле шигырь китаплары бастырып чыгарган.

Шагыйрь Камай авылында 1933 елның 20 декабрендә дөньяга килә. Бик яшьли ятим кала, әнисе һәм әбисе тәрбиясендә үсә. Авылда җидееллык, Бондюг эшчеләр бистәсендә урта мәктәпне тәмамлагач, Казан хәрби училищесында укый. 4 елга якын Совет армиясе сафларында хезмәт итә. Армиядән ул бер кочак шигырь, кулъязмалар күтәреп кайта. Хезмәтен тутырып кайткач, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатына эшкә урнаша, ләкин каләмнең тарту көче зуррак булып чыга. Дифгать Сирай Бондюг, Минзәлә, Калинин районы редакцияләрендә үзенең каләмен чарлый. Партия кушуы буенча инструктор, колхозда партком секретаре булып та эшләргә туры килә. Анда да сынатмый Дифгать абый. Урта белем белән генә ерак китеп булмаганын аңлаган егет, Алабуга педагогия институтына читтән торып укырга керә. Бераз мәктәптә укытып ала, аннан Балтач газетасы редакциясендә эшли. Мәскәүдә югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, гомеренең соңгы көннәренә кадәр «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында хезмәт куя.

Авылдашыбыз шагыйрь, журналист Дифгать Сираевның тууына 90 ел тулу уңаеннан Камай авылы китапханәсе әдәбият сөючеләрне «Туган яктан илһам алып» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәгә чакырды. Чара шигырьләр һәм җырлар белән үрелеп барды. Әлеге чарада шагыйрьнең кызлары, оныклары катнашты. Кызы Резеда ханым әтисе турындагы истәлекләр белән уртаклашты. Кичәдә Дифгать Сирай сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Әлеге очрашу һәркемнең күңелендә якты истәлек булып озак сакланыр, шагыйрьне искә алу кичәсе соңгысы булмас.

Гөлфидә ГАЛИМУЛЛИНА,
Камай авылы китапханәчесе

Әнкәй васыяте

Без үзебез дә олы яшьтә инде, тик әниебез Нурлыходаны сагынмаган бер генә көнебез дә юк. Ул пешергән ашның, бәлешнең тәме – тел очында, әйткән сүзләре – йөрәк түрендә. Әгәр исән булса, аңа быел 100 яшь тулган булыр иде. Биш бала тәрбияләп, бер генә тапкыр да ачуланганы булмады бит аның.

Без Сарман районындагы Хуҗи авылында туып-үстек. Әти белән әни – икесе дә агроном. Алар Нөркәй авылында тәҗрибә участогында эшләде. Бодайның төрле сортларын сынаган, районлаштырган өчен әнигә «Татарстанның атказанган агрономы» исеме бирелде. Бу тема эштә генә түгел, өйдә дә дәвам итә иде. Авылда беренчеләрдән булып 30 төп карлыган, алмагач, төрле җиләк-җимеш куаклары утыртты алар. Шуннан соң авылдашлар да бакчачылык белән шөгыльләнә башлады. Эшне беркайчан да бүлмәделәр. Әти пилмән ясаганда, кәбестә тозлаганда да әнигә булышты. Без – бәхетле балалар. Аларның матур гамәлләрен күреп, күңелгә сеңдереп үстек.

Әнинең тормышы җиңел булмый. Ул 1923 елда, ачлык үзәккә үткән елда туа. Әтисе Гыйльметдин 29 яшьлек чагында вафат була. Әбиебез Факия өч баланы тәрбияләп үстерә. Өстәвенә Гыйльметдин бабайның авыру апасы Гайшәне карарга кирәк. Факия әби аш-суга бик оста булды. Ул авыл халкына тәмле ризык – төш пешерә иде.

Бабай үлгәндә, кызым Нурлыхода – агроном, Тәгъзимә – хисапчы, Тәскирә укытучы булачак, дип әйткән. Аның сүзе рас килгән. Әнине Теләнче Тамак авылындагы МТСның орлыклар бүлегенә эшкә чакыралар. Аннан Арча районындагы Үрнәк техникумына укырга җибәрәләр. Әтием Гәрәфи белән шунда таныша алар. Әти – Наласа егете. Тик укып бетергәч, аны сугышка әзерләү өчен, Саратовка авиамеханика курсларына җибәрәләр. Әни исә Тәтеш техникумында укуын дәвам итә, төнлә исә ашлык маркировкалый. Әти армиядә хезмәт иткәндә әнигә: «Нурлыхода, исән-сау кайтсам, мин сиңа өйләнәм», – дип хат яза. Әни зәңгәр күзле, көләч йөзле иде. Тирә-якка гел яктылык чәчеп торды.

Биш бала үстек. Мин – Уфа нефть университетында академик. Әни минем академик Тимирязев кебек булуымны теләгән иде. Сеңелләрем Суфия – табиб, Нурия – укытучы, Гөлфия – контролер, Гөлия, әти-әни юлын дәвам итеп, башта агроном булып эшләсә, хәзер – социаль хезмәткәр. Шундый авыр заманнарда да биш балага югары белем һәм дөрес тәрбия биргән алар. Бу – үзе бер горурлык. Әни гел: «Укыгыз, белем алыгыз», – дигән сүзне кабатлады. Оныкларына да шулай диде. Колакка кергән бит! Алар төп нигезнең җылысын саклап яшәде.

Еллар үтсә дә, бер вакыйга һаман истән чыкмый. Элек авылда сарык, тавык тотсаң да, салым түләтәләр иде. Кемдер – йомырка, ит, кемдер йон белән бирде. Армиядә чакта минем өлешне дә сораганнар. Биш бала үстергән гаиләгә болай да җиңел түгел бит. Шулчакта әни миңа: «Улым, нишлим икән?» – дип хат язган иде. Шуннан соң командирдан: «Иптәш полковник, менә шундыйрак хәл килеп чыкты бит әле», – дип киңәш сорадым. Ул тиз генә Сарман районы хәрби комиссариатына шалтыратып, мәсьәләне бик тиз хәл итте. Әни җаным бик куанган иде ул чакта.

Әнисез яшәвебезгә 11 ел инде. Ул 89 яшьтә бакыйлыкка күчте. Әнисез бик авыр икән. Искә төшергән саен үзәкләр өзелә… Аның һәр киңәшен истә тотып, йөзенә кызыллык китермичә, хәләл көч түгеп яшәргә тырышабыз. Рухың шат булсын, әнкәй!

Роберт ШӘРӘФИЕВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары **Галиев** Артур Ирек улына **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәренең «Горводзеленхоз» су һәм агачлар-үсемлекләр утырту хуҗалыгы буенча шәһәр производство тресты» муниципаль унитар предприятиесе агач-үсемлекләр утырту эшчесе **Минвәлиева** Ильмира Хөснулла кызына, «Фламинго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Низамов** Альфред Альберт улына, «Буа-Водоканал» акционер җәмгыятенең экскаватор машинисты **Садыйков** Насих Кадим улына, «Әлмәт-Водоканал» акционер җәмгыятенең суның сыйфатын тикшерү тәҗрибә лабораториясе химик анализ лаборанты **Сергеева** Елена Вениаминовнага, «Коммуналь хуҗалык» муниципаль унитар предприятиесе директорының җитештерү буенча урынбасары (Зеленодольск шәһәре) **Фатыйхов** Рисхәт Фарса улына, «Әлмәт-Водоканал» акционер җәмгыятенең канализация чистарту корылмалары участогы канализация җиһазлары слесаре-ремонтчысы **Шәрипов** Рафикъ Илдар улына, «Балтачның күптармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы производство предприятиесе» акционер җәмгыятенең насос җайланмалары машинисты **Йосыпов** Хәлим Гариф улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Республиканың төзелеш тармагын күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Төзелеш» төзелеш оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Жиленков** Александр Николаевичка, «ПМК+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шәяхмәтов** Асыл Әсхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы мелиораторлары коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционер җәмгыяте җитәкчелеге, Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционер җәмгыятенең элекке генераль директоры урынбасары
ГАФУРОВ Ирек Баһаветдин улы
вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА МИНИМАЛЬ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӨНӘР БЕРЛЕКЛӘРЕ ФЕДЕРАЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АРАСЫНДА

КИЛЕШҮ

Казан шәһәре

2023 ел, 27 декабрь

«Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге (алга таба – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе) – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе Уставы нигезендә эш итүче рәисе Кузьмичева Елена Ивановна йөзендә, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы – Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләре координация советы турындагы нигезләмәгә таянып эш итүче рәисе Лаврентьев Александр Петрович йөзендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры Песошин Алексей Валерьевич йөзендә, алга таба Яклар дип атала, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясы, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеде:

1 статья

1. Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче хезмәткәрләр өчен (федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмаларның хезмәткәрләреннән тыш) 2024 елның 1 гыйнварыннан минималь хезмәт хакы аена 22 020 сум күләмендә билгеләнә.
2. Минималь хезмәт хакы 2023 елның II кварталына Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджетының кыйммәти зурлыгыннан 100 процент күләмендә билгеләнде һәм ул Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән эш вакытының айлык нормасын эшләгән һәм тариф ставкасын (окладын) яисә тарифсыз система буенча хезмәт хакын, шулай ук өстәп түләүләрне, өстәмәләрне, премияләрне һәм башка түләүләрне (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 147, 151 – 154 статьялары нигезендә башкарыла торган түләүләрдән тыш) үз эченә алган хезмәт нормасын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәүче хезмәткәргә түләнә торган түләүләрнең минималь суммасыннан гыйбарәт.
3. Татарстан Республикасында әлеге Килешү белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмалары һәм, юридик зат оештырмыйча, үз акчасы исәбеннән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан тәэмин ителә.
4. Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре өчен минималь хезмәт хакы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнә.
5. Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче һәм үзенә карата әлеге Килешү гамәлдә булган яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясында билгеләнгән тәртиптә әлеге Килешүнең гамәле кагылган эш бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы, әлеге хезмәткәр тарафыннан шушы чорда эш вакыты нормасы тулысынча эшләнү һәм хезмәт нормалары (хезмәт йөкләмәләре) үтәлү шарты белән, әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән түбән була алмый.
6. Әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме хезмәт өчен түләү буенча югарырак минималь гарантияләр билгеләүгә чикләү булып тормый.
7. 2024 елның II кварталы өчен тулаем Татарстан Республикасы буенча минималь куллану бюджетының хакы зурлыгыннан процент нисбәтендә билгеләнә торган минималь хезмәт хакы күләмен арттыруның киләсе срогы 2025 елның 1 гыйнварыннан билгеләнә. Минималь хезмәт хакы күләме Татарстан Республикасында алдан билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән түбәнрәк була алмый.
Чираттагы чорга Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында килешү әзерләү, төзү буенча күмәк сөйләшүләр һәм күрсәтелгән килешүгә имза кую Яклар тарафыннан 2025 елга Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру тәмамланганчы тәэмин ителә.

2 статья

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен Яклар:
Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган һәм әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылуын тәэмин итү буенча чаралар күрә, шул исәптән әлеге Килешүгә кушылудан баш тарткан эш бирүче вәкилләре һәм бу эш бирүче хезмәткәрләрен берләштергән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы вәкилләре белән консультацияләрдә катнаша;
шушы чорда эш вакыты нормасын тулысынча эшләгән һәм хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) башкарган хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы күләмен әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән түбән булмаган дәрәҗәдә хезмәт өчен түләү күләмнәрен билгеләү буенча чаралар күрә;
әлеге Килешүнең үтәлешен мониторинглауны гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләрен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе һәм аның эшче төркеме утырышларында елга кимендә бер тапкыр карап тикшерә.

3 статья

1. Әлеге Килешү төзелгәннән соң, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буларак, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган һәм әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләргә аңа кушылырга тәкъдим итә.
Әлеге тәкъдим бу Килешүнең тексты белән бергә «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында рәсми басылып чыгарга тиеш.
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге Килешүне һәм аңа кушылу турындагы тәкъдимне бастырып чыгару турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итә.
2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган эш бирүчеләр тарафыннан эш бирүчеләргә әлеге Килешүгә кушылу турында тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән 30 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге пункт белән билгеләнгән тәртиптә аңа кушылудан мотивлаштырылган язма баш тарту кәгазе җибәрелмәгән булса, бу Килешү әлеге тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән югарыда күрсәтеп үтелгән эш бирүчеләргә кагыла дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш. Баш тарту кәгазенә бу эш бирүченең хезмәткәрләрен берләштерә торган башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән консультацияләр беркетмәсе һәм хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын әлеге Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр арттыру сроклары турында тәкъдимнәр теркәлергә тиеш.
Әлеге эш бирүченең хезмәткәрләре нинди дә булса башлангыч һөнәр берлеге оешмаларына берләштерелмәгән яисә башлангыч һөнәр берлеге оешмаларының берсе дә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең яртысыннан күбрәген берләштермәгән һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән тәртиптә әлеге эш бирүченең барлык хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле булмаган очракларда, баш тарту кәгазенә эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә сайланган башка вәкиллекле орган (вәкиле) белән консультацияләр беркетмәсе һәм хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын әлеге Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр арттыру сроклары турындагы тәкъдимнәр теркәлергә тиеш.
3. Эш бирүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган, әлеге Килешүгә кушылу турындагы тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән соң төзелгән һәм үз эшчәнлеген башлап җибәргән юридик затлар, юридик зат булып оешмаган индивидуаль эшмәкәрләр, әлеге Килешүгә кушылу мөмкинлеге булмаган очракта, дәүләт теркәвенә алынган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге статьяның 2 пунктында каралган документлар белән бергә мотивлаштырылган язма баш тарту кәгазе җибәрергә хокуклы.
Әлеге мотивлаштырылган язма баш тарту кәгазе тапшырылмаган очракта, әлеге Килешү бу эш бирүчеләргә кагыла дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш.
4. Эш бирүче әлеге Килешүгә кушылырга баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең яклар вәкилләре катнашында консультацияләр үткәрү өчен бу эш бирүченең вәкилләрен чакырырга хокуклы.
Эш бирүче һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе вәкилләре бу консультацияләрдә катнашырга тиеш.
5. Эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылудан язма баш тарту кәгазьләренең күчермәләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

4 статья

1. Әлеге Килешү шартларының үтәлешен контрольдә тоту Яклар тарафыннан үзләре билгели торган тәртиптә турыдан-туры гамәлгә ашырыла.
2. Әлеге Килешүнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда, Яклар тиешле рәсми сорау алынган көннән 30 календарь көн эчендә моның өчен кирәкле барлык мәгълүматны бер-берсенә тапшырырга бурычлы.

5 статья

Әлеге Килешү Татарстан Республикасы икътисадының бюджеттан тыш секторы оешмаларына – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган, әлеге Килешүне төзегән яки әлеге Килешүнең 3 статьясында билгеләнгән тәртиптә әлеге Килешүгә кушылган юридик затлар, юридик зат булып оешмаган шәхси эшмәкәрләр.

6 статья

Әлеге Килешүнең шартларына Якларның үзара ризалыгы белән теләсә кайсы вакытта үзгәреш кертелергә мөмкин. Үзгәрешләр Килешү төзү өчен каралган тәртиптә кертелә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләмен киметә алмый.

7 статья

Әлеге Килешүне аңлатуга һәм куллануга бәйле рәвештә, Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

8 статья

1. Әлеге Килешү тексты түбәндәгеләргә җибәрелә:
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан – республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, шулай ук билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгаруга;
Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы тарафыннан – әлеге берләшмәләр составына керә торган оешмаларга;
Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе тарафыннан – республика тармак һөнәр берлекләре оешмаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең һөнәр берлекләре оешмалары координация советларына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы һөнәр берлекләре тармак комитетларына (советларына), Татарстан Республикасы предприятиеләренең, оешмаларының һәм учреждениеләренең башлангыч һөнәр берлекләре оешмаларына.
2. Әлеге Килешү тексты Якларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

9 статья

5.1. Әлеге Килешүгә бер үк юридик көчкә ия булган өч, һәр Як өчен берәр нөсхәдә кул куелды.

10 статья

Әлеге Килешү 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында яңа килешү үз көченә кергәнгә кадәр гамәлдә була.

Якларның имзалары:

Татарстан Республикасы Премьер-министры
А.В. Песошин

Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе
Е.И. Кузьмичева

Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы рәисе
А.П. Лаврентьев

ЭШ БИРҮЧЕЛӘРГӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӨНӘР БЕРЛЕКЛӘРЕ ФЕДЕРАЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АРАСЫНДА 2023 ЕЛНЫҢ 27 ДЕКАБРЕНДӘГЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА МИНИМАЛЬ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТУРЫНДАГЫ КИЛЕШҮГӘ КУШЫЛУ ХАКЫНДА

ТӘКЪДИМ

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы һәм әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләргә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2023 елның 27 декабрендәге Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турындагы килешүгә кушылырга тәкъдим итә.
Килешү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында 2023 елның 27 декабрендә 361 номер белән теркәлгән.
Әгәр Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр әлеге тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән 30 (утыз) календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына язма рәвештә югарыда күрсәтелгән Килешүгә кушылудан нигезле баш тарту тапшырмасалар, әлеге Килешү бу тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән соң әлеге эш бирүчеләргә таратылган дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.
Күрсәтелгән баш тартуга түбәндәгеләр теркәлергә тиеш:
әлеге эш бирүче хезмәткәрләрен берләштерүче беренчел һөнәр оешмасының сайланган органы белән эш бирүченең консультацияләре беркетмәсе,
2024 елда югарыда күрсәтелгән Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр.
Эш бирүче югарыда күрсәтелгән Килешүгә кушылудан баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге эш бирүче вәкилләрен, әлеге эш бирүчене берләштерә торган беренчел һөнәр оешмасының сайланулы органы вәкилләрен яисә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең бүтән вәкиллекле органы вәкилләрен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе яклары катнашында консультацияләр үткәрү өчен чакырырга хокуклы.
Эш бирүче вәкилләре, беренчел һөнәр оешмасының сайланган органы вәкилләре яки эш бирүче хезмәткәрләренең башка вәкиллекле органы вәкилләре һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе вәкилләре әлеге консультацияләрдә катнашырга бурычлы.
Эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылудан язмача баш тартулары күчермәләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

Татарстан Республикасы хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министры, Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең Хөкүмәт ягыннан координаторы

Э.Ә. Зарипова

Ватан хакына

Алар – безне, без аларны көтәбез...

Махсус хәрби операциядәге егетләр туган яктан килгән һәр күчтәнәчкә, хәтта кечкенә генә кәгазь почмагындагы хатка сөенә. «Ашарга да җитә, киемнәр дә бар. Туган як җылысын сагындык», – дигән иде Саба егете Илнар Хаев.

Күңел җылысын, яратуны һәркем үзенчә тапшырырга тырыша. Һәр район егетләр өчен кулдан килгәннең барысын да эшли. Чаллыдан 2 мең егет махсус хәрби операциядә катнаша. Чаллы мэры Наил Мәһдиев бер генә кешенең гаиләсен дә онытмый. Бәбиләре туса, аларны каршы ала, сабыйларны туган көннәре белән дә котлый, кирәк-яракларын алып бирә, кыскасы, егетләрне озатканда, гаиләгезне ташламыйбыз, дигән вәгъдәсенә тугры кала. Егетләрнең гаиләләрен дәүләт тә онытмый. Әтиләре махсус хәрби операциядәге егетләрнең балалары мәктәпләрдә бушлай туклана, бакчаларга, түгәрәкләргә, мәдәни һәм спорт чараларына бушлай йөри. Егетләр үзләре җирле салымнардан азат ителгән. Тагын шунысы бар: бары тик Чаллыда гына хәрбиләрнең яңа туган балаларына 100 мең сум акча бирелә.

– Хәрбиләрне онытмыйбыз. Наил Мәһдиев үзе егетләр янына 5 тапкыр барып кайтты. Ялга кайткан егетләр белән гел очрашып тора. Шәһәребездән СВОга 370 тоннадан артык гуманитар ярдәм җибәрелде, – ди мэр урынбасары Ирина Сәгыйдуллина.

Чаллы эшмәкәре Рөстәм Гатин да кыр кухнясына 80 миллион сумнан артык бәягә азык-төлек җибәргән. Алар Лисичанск халкын 5 миллион порциядән артыграк кайнар ризык белән тәэмин иткән.

Алабуганың «Без бергә» гуманитар штабы активистлары һәм яшь гвардиячеләр бу елда беренче гуманитар ярдәм партиясен озатты. Алар районның төрле оешмалары ярдәме белән кыр һәм төбәк госпитальләрендә яткан егетләргә 1,5 тоннадан артык гуманитар ярдәм җыйган. Алар арасында култык таяклары, коляскалар, юрганнар, подгузниклар, дарулар һәм хирургия кирәк-ярагы бар. Эшмәкәрләр Краснодон балалар интернатына да ярдәм юнәткән. Сабыйларга татлы бүләкләр, канцелярия товарлары, китаплар алып барганнар.

Зәй районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Марат Хәбибуллин сүзләренчә, егетләргә ярдәм бер генә минутка да туктап тормый. Районның һәр авылында солдатлар өчен җылы оекбашлар бәйлиләр, токмач кисәләр, окоп шәмнәре ясыйлар. Әле менә күптән түгел якташ егетләргә гуманитар ярдәм илтеп кайтканнар. «Зәй җылысы» хәйрия фондын оештыручылар Дмитрий Соловьев, Юрий Тимофеев бу юлы егетләргә «ГАЗель» машинасы илтеп биргән. Аны шәһәрнең бер оешмасы бүләк иткән.

– Хәрбиләргә буржуйкаларга ягу өчен бер тонна брикет, фольгоизолон, «КамАЗ», «Урал» машиналарына запас частьлар, пленкалар, генераторлар, бензин пычкылары, инструментлар, исемле посылкалар, тиз әзерләнә торган ашлар, окоп шәмнәре, йон оекбашлар, озак саклана торган ризыклар, маскировка челтәрләре һәм башка бик күп әйберләр алып бардык. Шулай ук мендәр-юрган, азык-төлек алып килүче кешеләр дә булды. Без бөтен күчтәнәчләрне дә илтеп тапшырдык, – ди Дмитрий Соловьев.

Саба районында «Хәят» коммерцияле булмаган оешма «Солдатка – өйдәге аш» акциясен башлап җибәргән. Әлеге оешма вәкиле Сатыш авылында яшәүче Гүзәл Садыйкова бу эшне башта гаиләсе белән башласа, инде хәзер саваплы эшкә бик күп кеше кушылган.

– Ирем Илфир яшелчә киптергеч сатып алып бирде. Хәрбиләргә кипкән аш ясаганнарын Сызрань хатын-кызларыннан күреп алдык. Телефон аша алар белән сөйләшеп, ашны ничек әзерләүләрен сораштык. Алар безгә онлайн мастер-класс күрсәтте. Бераз өйрәнгәч, эшкә тотындык, – ди Гүзәл.

Әлеге аш өчен ит тә, яшелчәләр дә киптерелә. Әзер чималны махсус пакетларга салалар. Күптән түгел егетләргә 200 пакет аш җибәргәннәр дә инде. 300 өлеш сохари да җибәргәннәр.

– Безгә башка авыллар да кушылды. 5 мең өлеш аш әзерләдек инде. Район эшмәкәрләре бик ярдәм итә. Аларга чиксез рәхмәт. Бу эшкә һәркем хәленнән килгәнчә өлеш кертә ала. Бигрәк тә бәрәңге, чөгендер, кишер, тозлы кыяр белән булышсалар яхшы булыр иде. Майсыз ит, кош ите кирәк, – ди Гүзәл. – Егетләргә ашны әзерләү җиңел булачак. Кайнар суда ул 10–15 минутта әзер була. Азык-төлек белән ярдәм итәргә әзер кешеләр булса, безгә мөрәҗәгать итсеннәр иде.

Ярдәмнең артыгы юк. Тәтеш районының Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Наталья Николаева шулай ди. Алар да якташ егетләргә нәрсә кирәк, шуны әзерләп җибәрәләр. Районлагы һәр оешмага, һәр кешегә чиксез рәхмәтле ул. Ә инде ялга кайткан егетләрнең рәхмәтен ишетү яңадан эшләр өчен канат куя икән. Шушы көннәрдә район башлыгы Рәмис Сафиуллов якташ егетләре белән очрашкан. Чәй өстәле янында егетләр район башлыгы белән сөйләшеп утырган. Барысы да гаиләләрен һәм үзләрен ташламаган өчен рәхмәт әйтә икән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Ак кына, кара гына...

Менә без барыбыз да белеп торабыз, бу дөнья фәкать актан гына тормый. Агы булган җирдә күге дә, карасы да, сорысы да килеп чыга. Төсләр ул, гомумән, бер-берсенә тагылып йөргән шикелле: барысы бергә һәм һәркайсы аерым.

Без акны яратабыз. Кызык инде, бер карасаң, ни өчен шул ак төскә бәйләнгәндер адәм баласы. Гомер буена салават күпере эчендә яшәп, акка сусаган да иреккә чыккан диярсең. Ап-ак карлар яуганын соклanып күзәтәбез. «Их, бәхет тә шулай яусын иде», – дип көрсенәбез дә якыннарыбызга ак бәхетләр телибез. Ак күңелле, ак уйлы кешеләргә ак юл теләп калабыз. Өметләребезнең аклануын көтәбез.

Без кешеләргә кара бәхет тә, кызылын да теләмибез. Зәңгәрен – күптән инде. Монысын без хәзер бөтенләй бозып, мәгънәсен үзгәртеп бетердек. Кеше күбрәк җыелган урыннарда ялгыш шул сүзне кычкырыбрак әйтсәң, әллә ничә адәм борылып карый: кайберләренең карашында шелтә, ачу, ә кайберләренекендә сагаю һәм яшерен өмет ялтырап китә...

Яшелнең дә мәгънәсе бераз бозылып бара, без аны хәзер табигать, тереклек символыннан бигрәк, яшел акча сурәтендә күзаллыйбыз. Берни дә кылып булмый торгандыр инде, заманы шулдыр: бу чор безне шулкадәр ярлыландырды, тормышыбызга ямь һәм тереклек бирүче иң зур нәрсәләрдән нибары акча калды. Акчаны – байлык, «Кара квадрат»ны шедевр дип уйлаган кешеләр арасында яшәү бик җиңел була алмый инде, ул әле кайвакыт беркадәр куркыныч та.

«Кара квадрат»ны ник син шулкадәр яратмыйсың, диләр. Белмим. Һәрхәлдә, кара булганы өчен түгел. Кара төснең дә үз матурлыгы бар. Без бит инде – кара җиргә кара тир агызып тәпи баскан егетләр. Квадрат булганы өчен дә түгел. Бергә уйнап үскән малайларның берише зур начальник булып китте хәзер. Йөзләре дә, гәүдәләре дә квадратка әйләнде. Шуларны ничек яратмыйсың ди инде?! Квадрат булган өчен генә түгел, начальник булганнары өчен яратырга бурычлысың. Туган илне сөю шуннан башлана, диләр бит хәзерге белгечләр. Гомумән, бүгенге түрәләрне һәрбер кеше яратырга тиеш, зур түрәләрне – зуррак мәхәббәт белән. «Кара квадрат»ны әйтәм... Хәтта сәнгать әсәре булмаганы өчен дә түгел. Сәнгатьтән ерак торган бөтен картиналарны да яратмый башласаң, нәфрәтеңнән шартлап, берәрсен пычратырга мөмкинсең. Белмим, әйтәлмим ни өчен икәнен. Тик «Кара квадрат» миңа картина түгел, ә кешелеккә куелган диагноз кебек тоела.

Акны – ак, караны кара дип әйтәсең бит инде. Ак каен, кара туфрак, дисең... Үз исеме белән атаудан гына бер нәрсәнең дә укасы коелып төшми. «Ак» дигәннән каен үрә сикерми, «кара» диюдән җир тетрәми. Җир кайчагында тетри, әлбәттә, тик колагыгызга киртеп куегыз, бала-чагагызга аңлатыгыз: бу аны «кара» дип атаганлыктан түгел. Тик кешеләр бераз башкачарак.

Без һәрвакыт ак булырга теләп яшибез. Хәтта ярамаган гамәл кылсак та, гаебебезне танырга атлыгып тормыйбыз, тизрәк акланырга ашыгабыз. Һәркем үзен ак дип атауны көтә. Аклык әйбәтлек билгесе кебек тоела. Югыйсә бер аермасы да юк бит инде – ак машина тапап үтерде ни, кара ни.

Алай түгел шул. Менә әйтеп кара син берәрсенә «кара йөзле» дип. Шундук дошманга әвереләсең. Хәтта Африкада туып-үсеп, төнен күзгә күренми торган кешегә әйләнә торган булса да, ул сиңа ачулана. Шул адәмгә «ак күңелле» дисәң... Белеп тора ич инде алдаганыңны. Аның күңелен беркайчан да күргәнең юк һәм булмаячак та икәнен аңлап тора. Үз күңелен аның хәтта үзенең дә күргәне юк, нинди төстә икәнен күз алдына да китерә алмый. Тик ышана. Сөенә. Балкып китә.

Караны ак дип әйтергә кирәк. Шулай итеп яшәсәң, бөтен кесәләрең савап белән тулачак. Юк, ялган булмый ул. Дөресме-ялганмы икәнне ачыклауның формуласы гади генә. Әгәр ике кеше ике төрле сүз сөйли икән, аның икенчесе ялгыша, ә беренчесе дөресен сөйли. Әгәр өч кеше өч төрле... ун кеше... мең кеше мең төрле сүз сөйли икән, аларның кайсы дөрес икәнен ачыклап йөреп булмый бит инде, «син алдашасың» дип, бер дәлилсез кимсетеп тә булмый. Шуңа күрә бу бәхәсле дөреслек була. Әгәр мең кеше бертөрле сүз сөйли икән, ул чын дөреслеккә әйләнә. Әгәр мең кеше караны – ак, акны кара дип тәкрарлый икән, димәк, алар хаклы.

Тик акны ак дип әйтергә ярамый. Болай дисәң, сиңа кешелекнең иң күп өлеше үпкәләячәк. Акны ак дигәнгә барысыннан да бигрәк сорылар рәнҗи. Чөнки алар үзләрен ак дип уйлыйлар. Барысы да аңлашыла бит инде, кара түгел, димәк, ак.

Ә тагы да яхшырагы – гомумән, бернәрсә дә әйтмәү. Кешеләр ул кадәр үк надан һәм синнән дә башсызрак түгел, акны карадан бик яхшы аералар. Тик беркем дә берни әйтми. Кара кеше кара эшләр кыла. Беркем дәшми. Ак адәм аклык чәчә. Дәшүче юк. Сүз әйтмәүчеләрнең тырнак астыннан кер эзләргә кирәкми, дәшми калу да җиңел түгел, ул да бик авыр һәм газаплы эш, бәлки, бераз бәхетсезлектер дә әле. Шул рәвешле, тормышның камиллеге хасил була: бер урында бернинди шау-шу юк, һәркем үз эше белән мәшгуль.

ӘДИЛӘ ХӘСӘНОВА:

«ТИНЧУРИН ТЕАТРЫ – ЯЗМЫШЫМДЫР»

«Хан кызы Турандык»та – горур, салкын канлы Турандык, «Ашина»да – гарип малай Мирза, «Җилкәнсезләр»дә – Дилбәр. Театр дөньясына ташкын булып килеп керде ул. Сүзебез Тинчурин театрының яшь актрисасы Әдилә ХӘСӘНОВА турында. Без аның белән нинди рольләрне якын итүе, образдан чыгу һәм кино турында сөйләштек.

:: Әдилә, ни өчен нәкъ менә театр өлкәсен сайладың? Актриса булу теләге кайчан барлыкка килде?

– Мин балачактан ук иҗади, сәнгатькә гашыйк бала булып үстем. 4–5 яшьләрдән үк биюгә йөрдем, музыка мәктәбендә укыдым, балет белән дә шөгыльләндем. Киләчәктә башка юлны сайлармын дип уйламадым да. Ә актриса булу, театрда эшләү теләге 7–8 нче сыйныфларда уянды. Мәктәптә театр түгәрәгенә йөри башлагач, һичшиксез, актриса булам, дидем. 9 нчы сыйныфны тәмамлап, Казан театр училищесына укырга кердем.

:: Тинчурин театрына ничек килеп эләктең?

– Казан театр училищесында мин Илдар абый Хәйруллин һәм Марсель Мәхмүтов курсын тәмамладым. Тинчурин театрына өченче курста укыганда килдем. Октябрь – ноябрь айлары иде. Ул вакытта без Илдар абый белән диплом эшенә әзерләнә башладык. Сергей Найденовның «Дети Ванюшина» әсәре буенча өзекләр әзерләдек. Шулай бер көнне Илдар абый безгә Тинчурин театрының баш режиссеры килүен әйтте. «Театрга яшьләр җитми, бәлки, берегез булса да күңеленә кереп калыр, кем булса да ошар», – диде. Икенче көнне без Туфан Имаметдиновка диплом эшләребездән өзекләр күрсәттек. Бер атнадан соң уңай хәбәр алдым. Аның белән училищеда очраштык һәм ул миңа Тинчурин театрында эшләргә тәкъдим итте. Әлбәттә, мин ризалаштым. Бу бит минем балачак хыялым иде! Тинчурин театрында эшләү ул – минем язмышымдыр. Чөнки мин Казанның Тинчурин урамында үстем. Беренче курстан ук башка театрларга караганда Тинчурин театры күңелемә якынрак булды. Мин үземне аның сәхнәсендә генә күрдем.

:: Беренче зур ролең турында сөйләшик. Училищеда укыганда ук сине Сәрдар Таһировский куйган «Хан кызы Турандык»тагы Турандык роленә билгелиләр. Моны ничек кабул иттең?

– Дүртенче курста укыганда шундый зур рольгә билгеләгәч, әлбәттә, башта каушадым. Курку хисе булды, чөнки Тинчурин театрында бик талантлы яшь актрисалар бар. Алар барысы да бу рольгә лаек дип саныйм. Миндә курку белән кыюлык көрәште. Мондый рольләргә мин үземне әле яшь дип саный идем. Тик үз көчемә, булдырып чыгуыма ышандым.

:: Нинди режиссерлар белән эшләгәнең бар? Кайсы күбрәк йогынты ясады дип уйлыйсың?

– Туфан Имаметдинов, Илнур Гарифуллин, Камил Гатауллин, Сәрдар Таһировский, Илсур Казакбаев белән эшләгәнем бар. Берсен дә аерып әйтә алмыйм, чөнки һәрберсе – үзенчәлекле режиссер, талантлы шәхес. Һәрберсенең үз алымы һәм һәрберсе мине яңа яктан ачты. Бу яктан мин аларга бик рәхмәтле.

:: Синең ике зур һәм истә калган рольләрең: горур хан кызы Турандык һәм «Ашина»дагы гарип малай Мирза. Кайсы авыррак бирелде?

– Берсе дә җиңел бирелмәде. Икесе дә зур мәхәббәт белән туды һәм башкарылды. Хан кызы – беренче төп ролем. Авырлыгы беренче чирканчык булуындадыр. Хезмәттәшләр алдында кыенрак иде. Чөнки син әле яшь, тәҗрибәң юк, ә сәләтеңне күрсәтергә кирәк. «Ашина»дагы Мирза – ул, әлбәттә, үзенчәлекле роль. Аны Ркаил Зәйдулла бөтенләй башкача язган, режиссер башкача күрде. Үзенчәлекле килеп чыкты.

:: Ә кайсы үзеңә якынрак?

– Гади рольләргә караганда, авыр һәм мине танырга авыр булган рольләр якынрак. Икесен дә бик яратам, икесе дә минем өчен бик кадерле. Турандык ул минем балам шикелле. Мирза – зур тырышлык һәм җаваплылык таләп иткән роль. Безнең театрда «Могҗиза» студиясе эшли. Анда мөмкинлекләре чикләнгән балалар йөри. Әзерләгәндә «барысы да бу спектакльне караячак» дигән уйлар да булды. Алар алдында да зур җаваплылык тойдым. Арттырмыйча, дөрес итеп күрсәтергә кирәк иде.

:: Сиңа образдан чыгу авыр бирелмәме?

– Укыганда Илдар абый әти-әниләребезгә: «Спектакльдән соң өйгә кайткач, балаларыгызга тимәгез, артык сораулар бирмәгез, тынычлансыннар», – дип әйтә иде. Рольгә кергәч, артык эмоцияләргә бирелсәң, күңелгә якын аласың. Һәм бу бик күп энергияне ала. Төрле рольләр була бит. Театрда эшли башлагач, әлбәттә, беренче елларда авыр иде. Хәзер дә кыен була әле. Илдар абыйның: «Сәхнәдә сез – актерлар, спектакль бетүгә сез образдан чыгарга тиеш. Артык күңелегезгә якын алмагыз. Профессионаллар шундый була», – дигән сүзләрен искә төшерәм.

:: Кинода төшү тәҗрибәң дә бар. Берсен сайларга кушсалар, кайсы – киномы, театрмы?

– Иң беренче мин «Татаркино» белән эшләдем. «Без – 41 нче ел балалары»н чыгардык. Анда мин Нина Комиссарова ролендә идем. Нурания Җамалиның «Юллар чатында» фильмында баш рольдә – Алия булдым. Узган ел ТНВ төшергән «Юллар чатында» сериалында Әдиләне уйнадым. Икесе дә – якын юнәлеш. Ә инде берсен генә сайларга дисәләр, театрны сайлар идем. Кинода күп әйберне төшереп, үзгәртеп була, ә спектакльдә хисләрне бер генә тоясың һәм аны үзгәртеп булмый.

:: Театр традицияләрне сакларга яки заман белән бергә атларга тиешме?

– Театр традицияләрне саклап, заман белән бергә атларга тиеш дип уйлыйм.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

СЫРНЫҢ ЭШЕ ЯСАГАЧ БАШЛАНА

Шөгыль

Сирәк эшләнә һәм мәшәкате күп булган табигый сырлар ясап, якыннарын сыйлаучы кешеләргә һәркем соклана. Азнакайда яшәүче Лилия Хөснуллина – гомеренең 33 елын аш-суга багышлаган әнә шундый үтә дә оста һәм тырыш ханымнарның берсе.

– Мин кечкенәдән үк аш-су тирәсендә кайнашырга ярата идем. Яшьли кияүгә чыкканлыктан, мәктәптән соң укуымны дәвам итмәдем. Олы кызымны алып кайткач, бер айлык күкрәк баласын әнигә калдырып, пешекчеләр курсына язылдым. Аны уңышлы гына тәмамлап, кулыма диплом алгач, гомерем буена җитәрлек һөнәр иясе булдым, – ди ул.

Яраткан һөнәренә бүген дә тугрылыклы ул. Хәзер инде эше өенә дә ияреп кайта, чөнки ул соңгы өч елда табигый сырлар ясау белән мавыгып киткән. Италия сыры – качокавалло, филатов пастасы, маасдам, качотта, буррата, шевр, фета, белпер кноле, камамбер... тагын әллә ниндиләр. Кыскасы, без күреп һәм тәмләп ияләшмәгән 40лап төрле сыр ясый Лилия ханым. Россия, Голландия сырларын да ясый, тик ят төрле сырлар арасында алары бер читтә торсын.

– Әлеге төрледән-төрле сырларны мин өч ел элек ясый башладым. Соңгы елларда саулыгым белән проблемалар барлыкка килгәнлектән, сәламәт туклануга күчтем. Балалар, оныкларымны да табигый, хәләл ризыклар белән сыйлыйсым килде. Сырларны өемдә ясый башлауның төп сәбәбе әнә шул. Аннан соң мин – тик торырга чыдый алмый торган, үтә дә кызыксынучан кеше. Шуның аркасында бер урында тик кенә утыра да белмим инде мин, – ди Лилия ханым.

Сыр ясау серләренә исә Казандагы мастер-классларга барып төшенә, атаклы сыр осталары Марина Каманина, Елена – Павел Куртинскийларның да онлайн дәресләрен ала.

Тик укыдың да тиз генә эшләп киттең түгел икән әле. Калган серләренә төшенергә дуслары ярдәм итә.

Лилия ханым сыр ясар өчен сөтне бары тик фермерлардан гына ала, чөнки аның сыйфатлы булуы мөһим. Оста әйтүенчә, гадәттә 10 кг сөттән 1 кг сыр чыга. Кайсы сырга кичке сөт тә ярый, кайсына бары тик иртәнге сөт кенә килешә икән. Иртәнгесе бәрәкәтлерәк тә була, сыры да күбрәк төшә.

– Сыр – бик нык төгәллек һәм чисталык яратучы ризык. Вакытны да күп ала. Аларны ясауда һәрберсенең үз технологиясе бар, һәркайсының өлгерү вакыты төрле. Әйтик, качокавалло – биш көннән, качотта 12 көннән өлгерә. 30, 45 көннән соң гына ашый торганнары да бар. Швейцария каты сыры бер елга кадәр дә тора ала. Анысы никадәр озаграк торса, шуның кадәр тәмлерәк. Килгән сөт башта суытыла. Аннан соң 65 градуска кадәр плитәдә җылытыла, шуннан соң кабат суытыла. Аннан оеткы эшләнелә. Миндә алар төрле, һәр сырныкы – үзенеке. Сырларга исә матур төсләрне табигый буягычлар (мәсәлән, шпинат, кофе, аннато) бирә, – ди ул.

Тик сырны ясап куйдың да эше бетте түгел икән әле. Һәркайсын карап, тәрбияләп торасы, өлгерер өчен уңай температура көйлисе, әйләндереп, кузгаткалап торасы бар.

– Һәр сырның үз холкы, үз тәме бар. Мин аларны кеше холыкларына охшатам хәтта. Ә тәмнәренә килгәндә, миңа барысы да якын, берсен дә аерып әйтә алмыйм. Ясаган һәр ризыгымны яратам, чөнки аларның һәркайсына кул җылым кергән. Ә менә эшләр өчен иң авыр сыр – бурратта. Ул чагыштырмача тиз, 7–8 сәгать эчендә эшләнә, тик буррата 85 градус кайнарлыктагы суда эшләнә. Минем инде куллар сизми дә аны хәзер. Пешкән сыман да түгел, ияләштем, – ди ул.

– Миңа бөтен әйбер матур булырга тиеш. Әзерләгән ризыгым, корган табыным, яшәгән өем, кигән киемем, эш урыным һәм, әлбәттә инде, аралашкан кешеләрем, – ди ул. – Иңне-иңгә куеп, 30 ел яшәгән ирем Рамилнең, ике кызымның, әниемнең, хезмәттәшем Ләйсәннең ярдәмнәрен һәрвакыт тоеп эшлим. Берьялгызым булсам, бу кадәр уңышларга ирешмәгән булыр идем. Әлбәттә инде, иң элек сайлаган һөнәреңне яратырга, күңелеңне биреп эшләргә кирәк дип уйлыйм. Шуңа күрә вакыт белән дә санлашмыйм. Төп эшемдә 8 сәгать эшләп кайткач, төнге икедә торып, сырлар ясый алам.

Ирешкән уңышлары, тапкан маллары булса да, бик тыйнак Лилия ханым.

– Мин үземне алай ук оста дип уйламыйм, – ди ул. – Өч ел бик аз вакыт, мин әле һаман да эзләнәм, алга барам. Эшлисе уй-хыялларым күп, гел яңалыкка омтылам, яңа курслар белән кызыксынам.

Ә без исә Лилия Хөснуллинага теләгән максатларына ирешеп, тырышлык белән килгән хезмәтенең бәрәкәтен күрүен телибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 4668 данә
Гомуми тираж – 13856 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 207

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+